К.С. Фәтхуллова, А.Ш. Юсупова, Э.Н. Денмөхәммәтова

ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘБЕЗ, УКЫЙБЫЗ, ЯЗАБЫЗ

Рус телендә сөйләшүчеләр өчен татар теле дәреслеге

Урта дәрәҗә

ГОВОРИМ, ЧИТАЕМ, ПИШЕМ ПО-ТАТАРСКИ

Учебное пособие по татарскому языку для русскоговорящих

Средний уровень

Казан

2015

УДК 811.512.145 : 811.161.1
ББК 81.2Тат : 81.2Р-4
Ф96

Рецензентлар:
З.Н. Кириллова – филология фәннәре кандидаты;
Г.А. Нәбиуллина – филология фәннәре кандидаты

Ф96 **Фәтхуллова К.С. һ.б.**
Татарча сөйләшәбез, укыйбыз, язабыз. Урта дәрәҗә. / К.С.Фәтхуллова, А.Ш.Юсупова, Э.Н.Денмөхәммәтова. — Казан: Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты, 2015. — 144 б. : ил.
ISBN 978-5-94113-000-0

Рәссамы *Мария Васильева*

Дәреслек үз эченә 18 теманы ала. Һәр тема аралашу ситуацияләренә бәйле тел һәм сөйләм берәмлекләрен гамәли үзләштерүгә кайтып кала. Дәреслекне укытучы җитәкчелегендә татар телен өйрәнү өчен дә, мөстәкыйль рәвештә үзләштерү өчен дә кулланып була. Дәреслек татар теле белән кызыксынучыларга һәм өйрәнүчеләргә тәкъдим ителә.

Учебное пособие включает в себя 18 тем. Каждая тема способствует усвоению речевых единиц, связанных с ситуацией общения. Пособие предназначено для изучения татарского языка как под руководством преподавателя, так и самостоятельно.

УДК 811.512.145 : 811.161.1
ББК 81.2Тат : 81.2Р-4

ISBN 978-5-94113-000-0

© Фәтхуллова К.С., Юсупова А.Ш., Денмөхәммәтова Э.Н., 2015
© Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты, 2015

Кадерле дуслар!

Сез татар телен өйрәнүне дәвам итәсез. Әлеге дәреслек ярдәмендә сез башлангыч дәрәҗәдә алган белемнәрегезне ныгытырсыз һәм сөйләм күнекмәләрегезне тагын да камилләштерә алырсыз. Дәреслек татар телен шәхесара һәм мәдәниятара аралашу чарасы буларак үзләштерү максатыннан төзелде һәм моның өчен кирәкле шартлар тудыра. Дәреслектә диалогик һәм монологик сөйләм үрнәкләре, фәнни-популяр текстлар һәм шигырьләр, күпсанлы тел һәм сөйләм күнегүләре урын алды. Алар сезгә татар телен гамәли үзләштерүдә ярдәм итәр.

Татар теле дәресләренә рәхим итегез!

Авторлар

***

Дорогие друзья!

Вы продолжаете изучать татарский язык. С помощью данного учебника вы углубите свои знания и сможете совершенствовать коммуникативные навыки. Учебник разработан с целью усвоения татарского языка как средства межличностного и межкультурного общения и создаёт для этого необходимые условия. В учебнике представлены образцы диалогических и монологических текстов, научно-популярные тексты и стихи, многочисленные языковые и речевые упражнения. Они помогут вам практически усвоить татарский язык.

Добро пожаловать на уроки татарского языка!

Авторы

Эчтәлек. Содержание

Тышкы кыяфәт. Внешний облик.......... 5

Иртәнге аш. Көндезге аш. Кичке аш. Завтрак. Обед. Ужин.......... 13

Татар ашлары. Татарская кулинария.......... 21

Көндәлек эшләр. Повседневные дела.......... 29

Гаилә бәйрәмнәре. Семейные праздники.......... 37

Ял итү урыннары. Места отдыха.......... 45

Дуслар белән аралашу. Общение с друзьями.......... 52

Яңа кешеләр белән танышу. Знакомство с новыми людьми.......... 61

Телләр өйрәнү. Изучение языков.......... 70

Татар теле. Татарский язык.......... 79

Татар диаспоралары. Татарские диаспоры.......... 88

Спорт бәйрәмнәре. Спортивные праздники.......... 96

Казан буйлап сәяхәт. Путешествие по Казани.......... 104

Татарстан шәһәрләре. Города Татарстана.......... 112

Татарстанның табигате. Природа Татарстана.......... 119

Үсемлекләр дөньясы. Мир растений.......... 125

Хайваннар дөньясы. Мир животных.......... 131

Сәяхәткә чыгабыз. Отправляемся в путешествие.......... 137

Гомуми тест. Общий тест.......... 163

Интернет ресурслары. Интернет-ресурсы.

1. http://www.suzlek.ru
2. http://www.belem.ru
3. http://kitap.net.ru
4. http://www.tat.com/tat-fr.html
5. http://anatele.ef.com
6. http://tatarile.org

ТЫШКЫ КЫЯФӘТ. ВНЕШНИЙ ОБЛИК

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Бу — Алсу. Аның күзләре кара, чәче коңгырт. Ул озын буйлы, сылу кыз.

Ә бу — Ясминә. Аның күзләре зәңгәр, чәче сары. Ул урта буйлы, матур кыз.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Динә, синең күзләрең нинди?

— Соры. Ә синеке, Әнисә?

— Яшел.



3. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз. Прослушайте, повторите и запомните.

кара күзле – кареглазый
коңгырт чәчле – брюнет (брюнетка)
сары чәчле – светловолосый

җирән чәчле – рыжеволосый
озын чәчле – длинноволосый
кыска чәчле – коротковолосый
бөдрә чәчле – кудрявый

озын буйлы – высокого роста
урта буйлы – среднего роста
кыска буйлы – низкого роста

чибәр – красивый
ябык – худой
симез – толстый
таза – крепкий, полный

4. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Гафу ит, бу кем?
— Бу — минем абыем.
— Исеме ничек?
— Бәхтияр.
— Аның күзләре нинди?
— Соры.
— Чәче нинди?
— Аксыл.
— Ул озын буйлымы?
— Әйе, аның буе 196 см. Ул баскетболчы.
— Ябыкмы? Тазамы?
— Бик ябык түгел.



5. Үрнәк буенча үзегез һәм дустыгыз турында әйтегез.

Скажите о себе и о друге (подруге) по образцу.

Минем күзләрем ... . Минем чәчем ... . Мин ... буйлы. Мин ябык.

Ә бу – минем дустым. Аның күзләре ... . Аның чәче ... . Ул ... буйлы. Ул симез.

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Бу әфәнденең чәчләре кыска.
...? Бу кызның күзләре соры.
...? Бу егет урта буйлы.
...? Миңа озын чәчле кызлар ошый.
...? Бу артистның күзләре зәңгәр.
...? Зилә ханымның күзләре кап-кара.
...? Бу зифа буйлы кыз — минем апам.
...? Бу чибәр кызлар — биючеләр.

7. Текстны укыгыз һәм үрнәк буенча үзегез турында сөйләгез.
Прочитайте текст и расскажите о себе по образцу.

Таныш булыгыз. Бу — Марат әфәнде. Аңа 33 яшь. Ул Казанда яши. Марат — укытучы. Ул мәктәптә эшли. Марат коңгырт чәчле, соры күзле, озын буйлы.

Марат өч тел белә. Ул русча, татарча, инглизчә сөйләшә. Марат телләр, музыка, спорт белән кызыксына.

8. Сорауларга җавап бирегез.
Ответьте на вопросы.

Бу малайның буе нинди?
Бу зифа буйлы кызның чәче нинди?
Бу кыска чәчле абый нинди?
Бу ябык ханымның буе нинди?
Ул кара чәчлеме?

Истә калдырыгыз! Запомните!

Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше
Склонение личных местоимений

Б.к.	Мин	Син	Ул	Без	Сез	Алар
И.к.	Минем	Синең	Аның	Безнең	Сезнең	Аларның
Ю.к.	Миңа	Сиңа	Аңа (аңарга)	Безгә	Сезгә	Аларга
Т.к.	Мине	Сине	Аны	Безне	Сезне	Аларны
Ч.к.	Миннән	Синнән	Аннан, аңардан	Бездән	Сездән	Алардан
У.-в.к.	Миндә	Синдә	Анда, аңарда	Бездә	Сездә	Аларда

9. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Миңа ... яшь. Минем күзләрем ... . Сезгә ... яшьме? Сезнең чәчегез ...? Син кайда ...? Сез безгә кайчан ...? Алар сиңа нәрсә ...? Аңа ... кирәк? Бездән аларга сәлам ... . Мин аны ... . Аңа нинди күзле ... ошый? Син ...? Сез ...? Алар ...? Сине кем ...? Аны кем ... ? Синдә татар китаплары ... ? Сез алардан ... кайттыгыз? Безгә ... әйтергә телисез?

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Минем дусларым — ... . Миңа ярдәмчел ... . Аңа миннән ... . Сез безгә ... . Аларның абыйсы ... . Әниемнең энисе ... . Дустым озын буйлы, чөнки ... . Минем чәчем озын, ә дустымныкы ... . Күзләрне сакларга ... . Минем апам ... .

11. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Исәнме, Алинә!
— Сәлам, Камилә!
— Алсу, бу кем?
— Бу — минем бабам.
— Аңа ничә яшь?
— 75.
— Ул кайда яши?
— Авылда.
— Син бабаңны яратасыңмы?
— Бик яратам. Ул да мине бик ярата. Җәйге каникулда мин һәрвакыт авылда яшим.

12. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— Сәлам!

— ... ! О-о-о-о, бу ... фотосы?

— Бу бит танылган ... . Беләсеңме ... ?

— Әйе, ... Ул шундый ... .

— Аның күзләре ... ?

— Минемчә, ...

— ... буйлымы?

— Юк, ...

— Ул сиңа ... ?

— ... ошый.

13. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) чәчле, кыска, абыем, һәм, күзле, зәңгәр, минем.
2) күзләре, сорымы, дустыңның, яшелме?
3) ошый, нинди, сиңа, кешеләр, буйлы?
4) кызның, кап-кара, бу, чәче.
5) теге, беләсеңме, чәчле, егетне, син, бөдрә, яхшы?

14. Дустыгызның фотосын күрсәтегез һәм аның турында сөйләгез.
Покажите фотографию подруги и расскажите о ней.

Бу — ... . Ул ... .

15. Яңа сүзләр төзеп әйтегез һәм тәрҗемә итегез.
Образуйте новые слова и переведите их.

1) Таза — ..., дус — ..., туган — ..., яшь — ..., матур — ... .
2) Күңел — ..., белем — ..., тәрбия — ..., итагать — ... .

-лык/-лек
-лы/-ле

16. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген сөйләгез.

Прочитайте текст и перескажите его содержание.

Минем дусларым күп. Аларның исемнәре — Наил, Зөфәр, Сөмбел, Җәмилә һәм Әлфинур. Без бер мәктәптә укыйбыз. Наил озын буйлы, коңгырт чәчле, соры күзле. Ул математика белән кызыксына, төрле олимпиадаларда катнаша, компьютерны яхшы белә. Зөфәр, киресенчә, кыска буйлы. Аның чәче сары, күзләре зәңгәр. Зөфәр бик матур җырлый. Ул татар, рус, инглиз җырларын башкарырга ярата. Үткән уку елында ул «Ел укучысы» конкурсында катнашты һәм Гран-при яулады. Без аның өчен бик шатландык. Зөфәр хәтта «Евровидение» конкурсында катнашырга хыяллана. Дустыбыз Сөмбел зифа буйлы. Аның күзләре дә, чәче дә кап-кара. Ул чын татар чибәре! Шуңа күрә «Татар кызы» конкурсында да ул беренче урынны алды. Сөмбел бик матур бии, берничә ел инде бию студиясендә шөгыльләнә. Ә менә Җәмилә — спортчы. Ул йөзү белән шөгыльләнә, кечкенәдән бассейнга йөри. Җәмилә кыска коңгырт чәчле, яшел күзле.

Мин дусларымны бик яратам. Алар белемле, тәрбияле, итагатьле, ярдәмчел, юмарт. Шундый дусларың булу — зур бәхет.

17. Җырдан өзекне сәнгатьле итеп укыгыз.

Прочитайте выразительно отрывок из татарской народной песни.

Чибәр кызга

(халык җыры)

Кашың кара, буең зифа,
Күзең дә кара синең,
Кара күзеңә карасам
Йөрәгем яна минем...
Кушымта:
Алма бакчасының юлы
Тәрәзәләргә туры.
Әллә сиңа биреләдеме
Бөтен дөньяның нуры?

18. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Какого цвета твои глаза?
2) Какого цвета глаза твоей подруги (твоего друга)?
3) Какой у тебя рост?
4) Вы знаете эту стройную девушку?
5) Тебе нравятся кудрявые парни?
6) Как зовут эту длинноволосую девушку?
7) Почему он такой худой?
8) Вы видите ту полную женщину? Кто она?
9) Знакомы ли Вы с тем голубоглазым парнем?
10) Кого Вы ищете? Вы можете сказать о внешнем облике этого человека?

19. Кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставив нужные слова.

1) Аның күзләре ..., чәче ....
2) Ул ... күзле, ... чәчле, ... буйлы.
3) Миңа ... чәчле, ... күзле, ... буйлы кешеләр ошый.
4) Минем дустымның күзләре ..., чәче ... . Ул ... буйлы.
5) Бу чибәр ... буйлы, ... күзле, ... чәчле кыз — минем ... .

20. Сүзләр белән җөмләләр төзеп языгыз. Составьте и запишите предложения со словами.
Озын чәчле, кара күзле, кыска буйлы, ябык, таза, чибәр, зифа буйлы.

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Ул ... буйлы.
1) озак 2) озын 3) кара

Алар кап-кара ... кыз белән таныштылар.
1) буйлы 2) күзге 3) күзле

Без бу зифа ... ханым белән таныш түгел.
1) ябык 2) буйлы 3) чәчле

Миңа ... чәчле егетләр ошый.
1) күзле 2) таза 3) чәчле

Бу ханымның буе ... .
1) уртача 2) симез 3) чибәр

Бу әфәнденең чәче ...
1) уртача 2) кыска 3) таза

Бу апа ...?
1) буйлымы 2) тазамы 3) җитмешме

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставляя нужные окончания.

Дустың... исем... ничек? Ул кайда яш...? Аның бу... нинди? Күзләре кара..., әллә зәңгәр...? Дустың нәрсә белән кызыксын...? Аның гаилә... ничә кеше? Дустың... абый..., апа... бармы?

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.

Үзегез турында сөйләгез.

ИРТӘНГЕ АШ. КӨНДЕЗГЕ АШ. КИЧКЕ АШ.
ЗАВТРАК. ОБЕД. УЖИН

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Әминә — укучы. Иртән ул сәгать җидедә тора. Иртән ул сөтле чәй эчә, солы яки дөге боткасы ашый.

Көндез ул ашханәдә ашый. Ул токмачлы аш, пылау яки ит белән бәрәңге ашарга ярата.

Кичке ашка Әминәнең әнисе яшелчә салаты ясады, балык кыздырды һәм карабодай боткасы пешерде.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Диләрә, син иртән нәрсә ашарга яратасың?
— Йомырка тәбәсе. Ә син, Зилә?
— Ә мин иртән каһвә эчәм, май белән күмәч ашыйм. Ботка яратмыйм.

3. **Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз.** Прослушайте, повторите и запомните.

ботка – каша
солы боткасы – овсяная каша
дөге – рис

ризык – еда
әзерләргә – готовить, печь
кыздырырга – жарить

карабодай – гречиха
пылау – плов
каһвә – кофе

йомырка тәбәсе – яичница
көндезге (төшке) аш – обед

4. **Үрнәк буенча диалог төзегез.** Составьте диалог по образцу.

— Алло, сәлам, Дамир!
— Сәлам, Салават!
— Хәлләр ничек?
— Бик яхшы, рәхмәт. Ә син нихәл?
— Ал да гөл.
— Бүген кичен кафега барабызмы?
— Кайсы кафега?
— Миңа «Биләр» кафесы ошый. Анда ризыклар бик тәмле.
— Ярый, мин риза. Кичкә кадәр. Сәгать алтыда кафеда очрашабыз.

5. **Үрнәк буенча үзегез турында әйтегез.** Скажите о себе по образцу.

Иртән мин сәгать алтыда торам. Иртәнге ашны сәгать җиденче яртыда ашыйм. Гадәттә мин какао эчәм, 1–2 йомырка ашыйм.

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Иртән без каһвә эчәбез.

...? Көндезге ашны мин кафеда ашыйм.

...? Кичке ашка әни пицца пешергән.

...? Мин карабодай боткасы яратам.

...? Бу кафеда балык ризыклары ашарга мөмкин.

...? Гафу итегез, бүген токмачлы аш юк.

...? Әбием сөтле чәй эчәргә ярата.

...? Бу ризык бик тәмле.

7. Текстны укыгыз һәм үрнәк буенча үзегез турында сөйләгез.
Прочитайте текст и расскажите о себе по образцу.

Бу — Әминә. Ул унынчы сыйныфта укый. Иртән ул сәгать җидедә тора, юына һәм иртәнге ашны ашый. Гадәттә ул сөтле чәй эчә, солы яки дөге боткасы ашый. Аннары Әминә мәктәпкә китә. Аларның мәктәбе Әминәләрнең өеннән ерак түгел. Шуңа күрә ул җәяү йөри. Көндезге ашны Әминә мәктәп ашханәсендә ашый. Анда төрле тәмле ризыклар пешерәләр. Әминә ашханәдә ашарга ярата.

Кичләрен ул үзе дә кичке аш әзерли. Ит белән бәрәңге пешерә, я балык кыздыра, ботка пешерә.

8. Сорауларга җавап бирегез. Ответьте на вопросы.

Малай иртән нәрсәләр ашый, нәрсә эчә?
Кыз кафеда төшке ашка нәрсәләр алган?
Бу әфәнде кичен нәрсәләр ашарга ярата?

Истә калдырыгыз! Запомните!

Бирегезче (бирегез әле) – дайте, пожалуйста

Әйтегезче (әйтегез әле) – скажите, пожалуйста

Кабатлагызчы (кабатлагыз әле) – повторите, пожалуйста

Ярдәм итегезче (ярдәм итегез әле) – помогите, пожалуйста

9. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Әйтегезче, бу нинди ...? Кабатлагыз әле, токмачлы аш ...? Сезгә ... салат кирәк? Син кайда ... яратасың? Сезгә карабодай боткасы ...? Иртән син нәрсә ...? Кичке ашны сәгать ничәдә ...? Син балык ...? Ул сөтле чәй ...?

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Бүген иртән мин ... . Миңа татар милли ризыклары ... . Миңа токмачлы аш ... . Карабодай боткасы ... . Дустым йомырка тәбәсе ... . Әнием балык ... . Мин кәбестә ашы яратам, ә апам ... . Иртәгә кичке ашны ... . Әтием иртән каһвә ... .

11. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Исәнме, Фирүзә!
— Сәлам, Халисә!
— Хәлләрең ничек?
— Рәхмәт, уртача. Син нихәл?
— Бик яхшы. Беләсеңме, мин икенче атнада Германиягә китәм. Анда өч ай укыячакмын.
— Чынлапмы? Синең өчен бик шат. Кайсы шәһәрдә булачаксың?
— Берлинда.
— Менә сиңа яңалык! Котлыйм. Әйдә, нәрсә ашыйбыз? Заказ бирик.
— Мин каһвә генә алам. Капучино. Ә син?
— Мин иртән ашамадым, шуңа күрә хәзер салат белән ботка алам.
— Яхшы.

12. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— Хәерле кич!

— ...!

— Әйдә әйт, кайсы кафега барабыз?

— ... . Ул шундый ... .

— Анда ... ашлары бармы?

— Минемчә, ...

— Ә сиңа тагын кайсы кафелар ...?

— ... .

13. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) ашарга, боткасы, иртән, яратам, дөге, мин.
2) әле, бармы, сездә, аш, токмачлы, әйтегез?
3) кирәк, кабатлагызчы, сезгә, нәрсә?
4) ярата, барырга, кафесына, «Биләр», кичләрен, дустым.
5) әле, бирегез, чәй, миңа, белән, лимон.

14. Рәсемгә карагыз һәм «Чәй йорты» турында сөйләгез.
Посмотрите на рисунок и расскажите о «Доме чая».

15. Яңа сүзләр төзеп әйтегез һәм тәрҗемә итегез. Образуйте новые слова и переведите их.

Иртән — ..., көндез — ..., кич — ..., җәй — ..., кыш — ..., яз — ..., көз — ... .

-гы/-ге
-кы/-ке

16. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген кыскача сөйләгез.
Прочитайте текст и перескажите его содержание.

Кичә без дусларыбыз белән «Әкият» кафесында ашадык. Ул шәһәр үзәгендә урнашкан. Бу кафе безгә бик ошый, чөнки балачакта без бик еш монда була идек. Хәзер дә, буш вакыт булганда, без анда очрашырга яратабыз. Кафеда ризыклар бик тәмле. Безгә бигрәк тә токмачлы аш, пылау, алма бәлеше бик ошый. Кафеда туңдырма да бик тәмле. Нинди генә сортлары юк! Без анда рәхәтләнеп ял итәбез, яңалыклар турында сөйләшәбез. Без барыбыз да спорт белән шөгыльләнәбез, шуңа күрә спорт яңалыклары һәркемгә кызык. Кичәге очрашуда без Сочи Олимпиадасы турында күп сөйләштек. Бер дустыбыз Олимпиада карарга барган. Ул безгә ачу тантасының матурлыгы, андагы спорт корылмалары, безнең спортчыларның уңышлары турында сөйләде.

Вакыт бик тиз, ләкин күңелле үтте. Дуслар белән очрашу — һәрвакыт бәйрәм ул.

17. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Прочитайте выразительно стихотворение.

Мин әнигә булышам

Әни пәрәмәч пешерә
Вак итеп, тәмле итеп:
Без табында чәй эчәбез
Бергәләп, тәмле итеп.

Мин дә булыштым әнигә
Пәрәмәчләр ясарга.
Үзең эшләгәч, тәмле ул —
Кирәк эшләп карарга!

Әзһәр Габиди

18. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Скажите, пожалуйста, у вас есть плов?
2) Дайте, пожалуйста, белый хлеб.
3) Ты любишь рисовую кашу?
4) Я завтракаю в восемь часов.
5) Приходите к нам на обед в воскресенье.
6) Вчера мы с друзьями ходили в кафе.
7) Вы хотите взять суп с лапшой?
8) Повторите, пожалуйста, что вы хотите взять?
9) Мама пожарила на ужин рыбу.
10) По утрам я обычно пью чай с молоком.

19. Кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставив нужные слова.

1) Иртән мин ... ашыйм, ... эчәм.
2) Көндезге ашны мин ... ашыйм.
3) Миңа ... бирегез әле.
4) Дустым ... ашарга ярата.
5) Шәһәребездә ... кафелар күп.

20. Сүзләр белән җөмләләр төзеп языгыз.
Составьте и запишите предложения со словами.

Әйтегез әле, бирегез әле, ярдәм итегез әле, җавап бирегез әле.

☑ ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ! ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Мин ... ашыйм.
1) сөт 2) чәй 3) аш

Алар кафеда ... боткасы ашадылар.
1) аш 2) дөге 3) каһвә

Без кичен җылы сөт ... .
1) пешерәбез 2) кыздырабыз 3) эчәбез

Миңа ... ашы ошый.
1) кәбестә 2) чәй 3) пилмән

Әбием ... кыздырырга ярата.
1) сөт 2) балык 3) аш

Бу әфәндегә ... бирегезче.
1) ипи 2) ашый 3) эчә

Бу кеше ... сорыймы?
1) бирегезче 2) пешерә 3) йомырка тәбәсе

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, используя нужные окончания.

Дустың нәрсә ашарга ярат...? Иртән син нәрсә эчә...? Кичә әниең нәрсә пешер... ? Иртәгә без дусларыбыз белән кафега бара... . Үткән атнада дусларың белән кайсы кафеда бул...? Миңа дөге боткасы бирегез... . Сездә пылау бар...?

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.

Иртән, көндез, кичен нәрсәләр ашарга яратуыгыз турында сөйләгез.



ТАТАР АШЛАРЫ. ТАТАРСКАЯ КУЛИНАРИЯ

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Бу — «Татар ашлары йорты» рестораны. Ә бу — «Биләр» кафесы.

Бу — гөбәдия. Ә бу — алма бәлеше.

Мин кыстыбый яратам, ә дустым өчпочмак ярата.

Бу — табын. Табында тәмле ризык.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Руслан, син нинди ризыклар ашарга яратасың?

— Миңа татар милли ашлары бик ошый.

— Ә кайсылары күбрәк ошый?

— Иң яраткан ризыгым — бәлеш. Дәү әнием бик тәмле пешерә. Ә син нәрсә яратасың, Җәүдәт?

— Ә мин коймак яратам. Минем дә әбием шундый тәмле пешерә, бармакларыңны йотарсың.

— Ә башка халыкларның милли ризыклары ошыймы соң?

— Әйе, миңа кытай ризыклары да бик ошый. Мин Кытайда булдым бит.

— Кызык. Ә менә мин итальян ризыкларын яратам, шуңа күрә дусларым белән итальян ресторанына йөрергә яратабыз. Сине дә чакырам.

— Рәхмәт.

3. **Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз.** Прослушайте, повторите и запомните.

камыр ашлары – мучные изделия
алма бәлеше – яблочный пирог
бәлеш – беляш

коймак – блинчики
пәрәмәч – перемяч
итле ризык – мясное блюдо

тәмле – вкусный
тәмсез – невкусный
баллы – сладкий

тозлы – солёный
майлы – жирный
ачы – горький

авыз итәргә – попробовать

4. **Сорауга җавап бирегез.** Ответьте на вопрос.

Кем нәрсә ярата?

Азат ... .

Әнәс ... .

Салават ... .



Бикә ... .



Зилә ... .

Динә ... .

5. **Үрнәк буенча әйтегез.** Скажите по образцу.

Минем яраткан ризыгым — бәлеш. Әбием бәлешне ит белән бәрәңгедән пешерә. Бәлеш бик тәмле була. Милли ашлардан миңа тагын гөбәдия ошый. Гөбәдия — баллы ризык.

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Камыр ашлары бик тәмле.

...? Казан кунакларына гөбәдия бик ошады.

...? Кичә без «Чәй йорты»на бардык.

...? Мин коймак пешерергә яратам.

...? Бу кафеда итальян ризыклары ашарга мөмкин.

...? «Бәхетле» кибетендә алма бәлеше алдым.

...? Ял көнне әбием бәлеш пешерде.

...? Дустыма төрек ризыклары бик ошый.

7. Текстны укыгыз һәм үрнәк буенча үзегез турында сөйләгез.
Прочитайте текст и расскажите о себе по образцу.

Бу — Мәликә. Ул Бөгелмәдә яши. Мәликә — укытучы. Ул инглиз телен укыта. Мәликә эшен бик ярата, балалар да аны яраталар. Ял көннәрендә Мәликә камыр ашлары пешерергә ярата. Аның яраткан ризыгы — пәрәмәч. Ул күп итеп пәрәмәч пешерә дә дусларын чәй эчәргә ярата. Аның дуслары да мәктәптә эшлиләр. Берсе — биология укытучысы, икенчесе тарих укыта.

Алар пәрәмәч белән чәй эчәләр, мәктәп һәм укучылары турында сөйләшәләр, рәхәтләнеп ял итәләр. Мәликә бик кунакчыл.

8. Сорауларга җавап бирегез.
Ответьте на вопросы.

Малай нәрсә ашый?
Кыз нәрсә ашарга ярата?
Әби нәрсә пешерә?

Истә калдырыгыз! Запомните!

Теләк белдерә торган аналитик фигыльләрнең төрләнеше

Спряжение аналитических глаголов, выражающих желание

минем ашыйсым килә	безнең ашыйсыбыз килә
синең ашыйсың килә	сезнең ашыйсыгыз килә
аның ашыйсы килә	аларның ашыйсылары килә

Юклык формасы: аның ашыйсы килми; безнең эчәсебез килми; аларның пешерәселәре килмәде; синең барасың килмәде.

9. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Минем ... ашыйсым килә. Синең ... эчәсең килә? Сезнең ... барасыгыз киләме? Сездә ... бармы? Синең кайсы ... очрашасың килә? Аларның «Чәй йорты»нда ... ашыйсылары килә. Аның ... пешерәсе килми. Дустымның ... ризыкларын авыз итәсе килә.

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Минем яраткан ризыгым — ... . Синең нәрсә ...? Аның сөтле чәй ... . Сезнең кафега ...? Аларның татар ашларын ... . Дустымның коймак пешерергә ... . Минем варенье белән ... . Кызларның бәлеш ... . Апамның туган көнен ... . Итальян ресторанында минем ... .

10. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Исәнме, Алмаз!

— Сәлам, Булат!

— Хәлләр яхшымы?

— Шәп, рәхмәт.

— Алмаз, әйдә, кафега барабыз!

— Кайчан?

— Хәзер.

— Кайсы кафега?

— «Якитория»гә. Мин суши яратам бит.

— Яхшы, риза. Әйдә, киттек. Минем дә ашыйсым килә.

11. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— Сәлам!
— ... !
— Бүген ... туган көне. Беләсеңме?
— Әйе, ... Котларга барабызмы?
— ... . Туган көн бәйрәме ... була?
— Минемчә, ... кафесында.
— ... ничәдә?
— ... . Син аңа нәрсә бүләк итәргә ... ?
— ... . Ә син?
— Минем ... бүләк итәсем килә.
— Яхшы, ... кадәр.

13. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) килә, минем, ашыйсым, бәлеше, алма.
2) кемнең, килә, кыстыбый, ашыйсы?
3) ошый, бик, дусларыма, рус, ашлары, камыр.
4) килә, эчәсе, чәй, сөтле, әбиемнең.
5) әле, әйтегез, бармы, аш, токмачлы, сездә?

14. Интернеттан татар ашлары турында мәгълүмат табыгыз һәм берсен әзерләү турында сөйләргә әзерләнегез.
Найдите в Интернете информацию о татарских блюдах и подготовьтесь рассказать о приготовлении одного из них.

15. Яңа сүзләр төзеп әйтегез һәм тәрҗемә итегез. Образуйте новые слова и переведите их.

-лы/-ле

Бал — ..., тәм — ..., тоз — ..., файда — ...,
токмач — ..., сөт — ..., май — ... .

16. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген кыскача сөйләгез.
Прочитайте текст и перескажите его содержание.

Кичә дустым Зөлфәтнең туган көне булды. Без «Татар ашлары йорты» ресторанында бәйрәм иттек. Монда ризыклар бик тәмле. Без төрле салатлар, ит ризыклары, камыр ашлары ашадык. Чәкчәк белән бик тәмле чәй эчтек. Талкыш кәләвә дә авыз иттек. Бәйрәмдә без сигез кеше булдык. Барлык дуслары да Зөлфәткә сәламәтлек, уңышлар, бәхет теләделәр. Алар аңа бик кызыклы бүләкләр бирделәр. Мәсәлән, Зөһрә белән Артур аңа волейбол тубы бүләк иттеләр, чөнки Зөлфәт җәен пляжда волейбол уйнарга ярата. Фирүзә белән Самат аңа яңа портфель алганнар, чөнки Зөлфәт күптән түгел банкта эшли башлады. Аңа яңа портфель бик килешә. Ә менә Антон яраткан дустына беләсезме нәрсә бүләк итте? Джаз концертына билет! Зөлфәт бик шатланды. Ә без Кәрим белән аңа «Спортмастер» кибетенә сертификат бүләк иттек. Нәрсә аласы килсә, шуны сайлар! Дуслар белән туган көн бәйрәмен үткәрү бик тә күңелле! Ә сез дусларыгызны ничек котлыйсыз?

17. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Прочитайте выразительно стихотворение.

Кичәгенәк

Йокыдан уяну белән
Бүген иртән:
— Чәй бир әле, зинһар, —
Диде Рөстәм.
Әни әйтте:
— Башта, улым,
Юынырга кирәк.
— Бик әйбәтләп юындым бит
Кичәгенәк.
Көлде әни:
— Алай булгач,
Бик шәп. Бик шәп...
Син бит чәй дә
эчкән идең
Кичәгенәк.

Шамил Маннап

18. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Мне хочется купить губадию в магазине «Бәхетле».
2) С чем ты хочешь пить чай?
3) Мой друг очень любит перемячи.
4) Вы знаете, как называется это блюдо?
5) Тебе нравятся мучные изделия?
6) Мне хочется приготовить чакчак.
7) Почему Вы не любите мясные блюда?
8) В воскресенье я испеку яблочный пирог и приглашу друзей на чаепитие.
9) Ты нашёл рецепт этого блюда?
10) Что нужно для приготовления домашней лапши?

19. Кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставляя нужные слова.

1) Аның ... ашыйсы, ... эчәсе килә.
2) Минем ... пешерәсем һәм ... чакырасым килә.
3) Безнең дустыбызга ... бүләк итәсебез килә.
4) Сезнең ... кафеда ашыйсыгыз килә?
5) Синең кемнәр белән ...?

20. Сүзләр белән җөмләләр төзеп языгыз. Составьте и запишите предложения со словами.
Пешерергә, ашарга, эчәргә, баллы, тәмле, камыр ашлары, ит ашлары.

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Аның ... пешерәсе килә.

1) бал 2) балык 3) баллы

Аларның ... ашыйсылары килә.

1) тозлы 2) тоз 3) бәлеш

Безнең сиңа ... бүләк итәсебез килә.

1) туп 2) тар 3) тугыз

Миңа ике кило ... кирәк.

1) ил 2) ит 3) илле

Бу ханымның ... чәй эчәсе килә.

1) токмачлы 2) тозлы 3) сөтле

Бу әфәнденең кибеттә ... аласы килә.

1) кырык 2) кыстыбый 3) татар

Сез бу ... авыз иттегезме?

1) ризыкны 2) тазамы 3) җидеме

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставляя нужные окончания.

Дустың... нәрсә ашыйсы кил...? Аларның кафе... нәрсә аласылары килә? Без... менә бу торт... бирегез әле. Әйтегез..., бу алма баллы...? Дустым... чаңгы бүләк итәсе... килә. Аның гаилә... белән кафе... барасы килә? Безнең камыр ашлары пешерәсе... килә.

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.

Яраткан милли ашларыгыз турында сөйләгез.



КӨНДӘЛЕК ЭШЛӘР. ПОВСЕДНЕВНЫЕ ДЕЛА

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Сәгать сигез. Мәктәптә дәресләр башлана.

Сәгать унике. Без ашханәдә төшке ашны ашыйбыз.

Кичке алты. Әни эштән кайта. Без гаилә белән кичке ашны ашыйбыз.

Кичләрен мин Интернеттан яңалыкларны укырга, музыка тыңларга яратам.

Ял көннәрендә без бассейнга йөрибез, кинога яки театрга барабыз.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Диләрә, син иртән ничәдә торасың?
— Җидедә.
— Ничәдә университетка китәсең?
— 7 сәгать 45 минутта.
— Гадәттә, сәгать ничәгә кадәр укыйсыз?
— Дүрткә кадәр.
— Кичләрен нишлисең?
— Өй эшен эшлим. Аннары ял итәм, төрле журналлар укырга яратам.

3. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз. Прослушайте, повторите и запомните.

берсекөнгә – послезавтра
былтыр – в прошлом году
өченчекөн – позавчера

быел – в этом году
соңыннан – после
аннан соң – затем

бераздан – через некоторое время

кунакка йөрергә – ходить в гости
аралашырга – общаться

тәкъдим итәргә – предлагать
канәгать булырга – быть довольным

4. Үрнәк буенча диалог төзегез. Составьте диалог по образцу.

— Алло, сәлам, Дәлия!
— Сәлам, Зилия!
— Хәлләр ничек?
— Рәхмәт, яхшы. Ә син нихәл?
— Беркөе. Бүген кичен эшләрең күпме?
— Күп түгел. Кая барырга тәкъдим итәсең?
— Әйдә, татар театрына барыйк әле. Анда бүген премьера. «Мәхәббәт FM» спектакле.
— Билетлар бармы соң?
— Таптым инде. Алайса җиденче яртыда театр янында көтәм.

5. Үрнәк буенча үзегез турында әйтегез. Скажите о себе по образцу.

Иртән мин җиденче яртыда торам. Сигезенче яртыда эшкә китәм. Кичке алтыга кадәр эшлим. Мин — сатучы, «Тандем» сәүдә-күңел ачу үзәгендә эшлим. Эшем миңа бик ошый. Кичләрен мин дусларым белән аралашырга, алар белән кинога, кафега йөрергә яратам. Ял көннәрендә без бергәләп тимераякта шуабыз, ә җәй көне пляжда кызынабыз, су керәбез, волейбол уйныйбыз.

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Бүген мин табибка барырга тиеш.

...? Кичә без дустыбызның туган көненә бардык.

...? Кичләрен ул татар газеталарын укырга ярата.

...? Миңа чаңгы спорты бик ошый.

...? Безнең «Рәйхан» кафесына барасыбыз килә.

...? Гафу итегез, бүгенге спектакльгә билетлар юк инде.

...? Әбием безне коймак белән сыйлады.

...? Вакытны файдалы үткәрергә кирәк.

7. Текстны укыгыз һәм үрнәк буенча үзегез турында сөйләгез.
Прочитайте текст и расскажите о себе по образцу.

Илдар — тарихчы. Ул мәктәптә укытучы булып эшли. Илдарга эше бик ошый, чөнки ул балаларны ярата. Дәресләрдә ул укучыларын борынгы цивилизацияләр, төрле тарихи вакыйгалар белән таныштыра. Укучылары аны игътибар белән тыңлыйлар, сораулар бирәләр. Илдар аларга тарихтан төрле кызыклы китаплар укырга, Интернетта материаллар табарга куша. Балалар бик күп мәгълүмат беләләр һәм алар турында сөйлиләр. Каникулда Илдар укучыларын музейларга алып бара, Татарстан тарихы белән таныштыра. Былтыр алар Болгарга да бардылар, андагы тарихи истәлекләрне күрделәр. Экскурсия балаларга бик ошады.

Илдарның укучылары тарихтан олимпиадаларда да катнашалар, призлы урыннар алалар. Укытучы алар белән горурлана.

Кышларын ял көннәрендә Илдар чаңгыда, тимераякта шуарга ярата, ә җәйләрен дуслары белән походка бара. Алар анда балык тоталар, балык ашы пешерәләр, шашлык кыздыралар, учак янында тарих турында бәхәсләшәләр.

Илдар тормышыннан бик канәгать.

8. Сорауларга җавап бирегез. Ответьте на вопросы.

Малай нәрсә белән кызыксына?
Кыз буш вакытында нәрсә белән шөгыльләнә?
Бабай кичләрен нишләргә ярата?

Истә калдырыгыз! Запомните!

Ниятне белдерә торган аналитик фигыльләрнең төрләнеше.

Спряжение аналитических глаголов, выражающих намерение.

Мин бар**макчы булам**	без бар**макчы булабыз**
Син бар**макчы буласың**	сез бар**макчы буласыз**
Ул бар**макчы була**	алар бар**макчы булалар**

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Җәен дусларым Кытайга бармакчы булалар, чөнки ... . Мин Татарстан тарихы белән кызыксынам, шуңа күрә ... . Алмаз тау чаңгысы белән шөгыльләнмәкче була, ләкин ... . Ял көнне сез кая ...? Алар кайсы музейга ...? Без әбиемнең туган көненә ... . Дустым Америкага укырга китмәкче була, ә мин ... . Укытучыбыз безне Санкт-Петербургка ... . Кызлар бию студиясенә йөрмәкче булалар, чөнки ... . Малайлар шахмат ярышларында ... .

11. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Алмаз, сәлам!

— Сәлам, Нияз!

— Алмаз, ял көнне нишләмәкче буласың?

— Белмим әле. Син нәрсә тәкъдим итмәкче буласың?

— Әйдә, авылга кайттыйк әле. Бабайга ярдәм итәргә кирәк.

— Яхшы. Сәгать ничәдә китәбез?

— Минемчә, иртәнге автобус белән китәргә кирәк. Сәгать алтыда.

— Сөйләштек. Иртән алтынчы яртыда автовокзалда очрашабыз алайса.

12. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— Хәерле иртә!

— ...! Без бүген укытучыбыз белән ... бармакчы булабыз.

— Сәгать ...?

— Нәрсә белән ...?

— Минемчә, ...

— Анда сәгать ничәгә кадәр ...?

— Көн буе. Сәгать ... кайтачакбыз.

— Ярый, хәерле юллар! Исән-сау йөрегез!

— ... .

13. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) вакытымда, мин, яратам, романнар, тарихи, укырга, буш.
2) көнне, буласыз, ял, бармакчы, кая, сез?
3) була, дустым, каникулда, китмәкче, җәйге, Германиягә.
4) кызлар, булалар, конкурсында, катнашмакчы, матурлык.
5) саен, мин, белән, танышам, көн, танышам.

14. Көн саен сез нәрсәләр эшлисез? Шул турында сөйләгез.
Что вы делаете изо дня в день? Расскажите об этом.

15. Яңа сүзләр төзеп әйтегез һәм тәрҗемә итегез. Образуйте новые слова и переведите их.

Кич — ..., кыш — ..., яз — ..., көз — ...,
җәй — ..., иртә — ... .

-ын/-ен

Истә калдырыгыз! Запомните!
Еш (часто), **сирәк** (редко), **күп** (много), **бераз** (немного),
һаман (всё время, постоянно), **озак** (долго), **ара-тирә** (иногда, временами),
бөтенләйгә (навсегда), **гомергә** (навеки) —
күләм-чама рәвешләре (наречия меры и степени).

16. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген кыскача сөйләгез.
Прочитайте текст и перескажите его содержание.

Таныш булыйк: минем исемем — Илнур. Мин — программист, компьютерлар белгече, зур сәүдә фирмасында эшлим. Эшемнән мин бик канәгать, хезмәттәшләрем дә бик яхшы, ярдәмчел кешеләр.

Буш вакытымны мин дусларым белән үткәрәм. Алар — бик кызык кешеләр. Ял көннәрендә без алар белән еш очрашабыз һәм төрле темаларга сөйләшәбез. Бигрәк тә яшьләр тормышы, спорт, музыка яңалыклары, яңа технологияләр безне кызыксындыра. Шул ук вакытта үзебезнең тормышыбыздагы күңелле хәлләр турында бер-беребезгә хәбәр итәбез.

Менә кичә кичен без «Салават күпере» кафесында очраштык. Башта бөтен сөйләшүләр Сочи Олимпиадасы турында булды. Һәркем Кышкы Олимпиада ярышлыран яратып карый, безнең спортчылар өчен җан ата. Кызлар, әлбәттә фигуралы шуу турында бик күп сөйләделәр, Россия командасының алтын медаль яулап алуы, спортчыларыбызның көчле һәм матур булулары турында әйттеләр. Егетләр исә һаман хоккейны сөйлиләр. Артур биатлон ярышларын карарга ярата икән. Ул безгә иң көчле биатлончылар турында әйтеп үтте. Аннары спорттан мәдәнияткә күчтек. Мәдинә Шаляпин исемендәге халыкара опера фестивале турында әйтеп үтте. Ул инде ике тапкыр театрда булган. Башкалар да ара-тирә театрга йөриләр, ләкин вакытлары җитми. Шуңа күрә Мәдинәне кызыксынып тыңладык. Озак кына шулай сөйләшеп утырдык, һәрберебез өчен очрашу, аралашу күңелле булды. Гомерлек дусларың булу — зур бәхет ул.

17. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Прочитайте выразительно стихотворение.

Эш һәм белем

Эшчән кеше булу — бик зур бәхет.
Эш ул — бу тормышның үзәге.
Укый-яза белү — шул тормышның
Җәүһәр төсле матур бизәге.

Мәҗит Гафури

18. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Куда намереваешься ехать летом?
2) Как зовут эту девушку? Кем она работает?
3) Чем занимаешься в свободное время?
4) Часто ли бываете в театре?
5) Какие виды спорта нравятся тебе больше всего?
6) Вы смотрели репортажи с Сочинской Олимпиады?
7) Почему ты не пришел на встречу в прошлое воскресенье?
8) С кем вы любите общаться?
9) Скажите, пожалуйста, у вас есть книга про историю Булгар?
10) Что вы знаете о культурно-развлекательных местах Казани?

19. Дөрес языгыз. Напишите правильно.

1) Мин урманга бармакчы була... .
2) Ул чит илдә ял ит... була.
3) Без спорт ярышларында катнаш... булабыз.
4) Дустым бию студиясендә шөгыльлән... була.
5) Алар тимераяк... шуарга яраталар.

20. Сүзләр белән җөмләләр төзеп языгыз. Составьте и запишите предложения со словами. Быел, былтыр, кичен, иртән, кышын, җәен, еш, сирәк.

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Ул Төркия... ял итмәкче була.
1) -да 2) -дә 3) -гә

Алар музыка фестивале... катнашмакчы булалар.
1) -дә 2) -нә 3) -ндә

Без спорт ярышлары... карарга яратабыз.
1) -на 2) -нда 3) -н

Мин Болгарга экскурсия... бармакчы булам.
1) -га 2) -дә 3) -гә

Кайбер студентлар ара-тирә генә китапханә... булалар.
1) -гә 2) -дә 3) -дән

Җәен балалар «Сәләт» лагере... бик күңелле ял иткәннәр.
1) -нда 2) -ндә 3) -на

Без күп вакытыбыз... саф һавада үткәрергә тиеш.
1) -да 2) -ны 3) -дан

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставляя нужные окончания.

Дустым Яңа елда Мәскәү... булган. Без классик балет фестивале... бармакчы булабыз. Укучылар шахмат ярышы... беренче урын алдылар. Кызлар... фигуралы шуу бик ошый. Без мәктәп дусларыбыз белән ара-тирә очраша... . Гафу итегез, Болгар... ике билет бирегез әле. Бу галим Татарстан тарихы турында яңа китап яз... була.

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.

Көндәлек эшләрегез турында сөйләгез.



ГАИЛӘ БӘЙРӘМНӘРЕ. СЕМЕЙНЫЕ ПРАЗДНИКИ

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Алсуның апасы бар. Аның исеме — Таңсылу.

Таңсылу — тәрбияче. Ул балалар бакчасында эшли.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Алсу, кичә сездә нинди бәйрәм булды?

— Апамның туе.

— Шулаймыни? Таңсылу кияүгә чыктымыни?

— Әйе. Алмазга кияүгә чыкты. Алар озак йөрделәр бит инде.

— Туй мәҗлесе кайда булды соң?

— «Сәфәр» кунакханәсе ресторанында.

— Кунаклар күп булдымы?

— Бик күп. Таңсылу белән Алмазның дуслары, хезмәттәшләре, туганнарыбыз.

— Туй ошадымы соң?

— Әлбәттә инде. Барысы да рәхәтләнеп күңел ачты.

— Ярый. Яхшы булган. Яшьләрне котлыйм. Бәхетле булсыннар.

— Рәхмәт.

3. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз.
Прослушайте, повторите и запомните.

туй – свадьба
мәҗлес – торжество
өй туе – новоселье

бәби туе – роди́ны
чакырырга – приглашать
никах – никах

кияү – жених
кәләш – невеста

кияүгә чыгарга – выходить замуж
өйләнергә – жениться
өйләнешергә – пожениться

4. Үрнәк буенча диалог төзегез. Составьте диалог по образцу.

— Алло, Диләфрүз!
— Сәлам, Дамир!
— Миләүшә белән Динарның туе кайчан?
— Иртәгә.
— Кайда?
— «Туган авылым» ресторанында.
— Яхшы, рәхмәт. Иртәгә туйда очрашырбыз.

5. Үрнәк буенча әйтегез. Скажите по образцу.

Хөрмәтле Нажия апа!
Сезне туй мәҗлесебезгә чакырабыз. Мәҗлес 2014 елның 14 нче августында «Тургай» кафесында (Татарстан урамы, 22) 18.00 сәгатьтә башлана.
Зөлфәт, Тәнзилә.

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Иртәгә дустымның туена барам.

...? Кичә туганнарыбыз өй туен бәйрәм иттеләр.

...? Киявебезнең исеме — Кәрим.

...? Миңа өй туена бүләк алырга кирәк.

...? Апамның туенда барысы да рәхәтләнеп күңел ачты.

...? Гаилә бәйрәмнәре турында кызыклы мәгълүмат укыдым.

...? Әлфинур мине туй мәҗлесенә чакырды.

...? Туйлар август аенда күп була.

7. Текстны укыгыз һәм үрнәк буенча үзегез турында сөйләгез.
Прочитайте текст и расскажите о себе по образцу.

Без Таңсылу белән Алмазның туенда булдык. Алар август аенда өйләнештеләр. Туй мәҗлесе «Сәфәр» кунакханәсе ресторанында узды. Башта яшьләрне кияү белән кәләшнең әти-әниләре котлады. Алар Алмаз белән Таңсылуга чын мәхәббәт, бәхет һәм шатлыклар, тигез гомер һәм сәламәтлек теләделәр. Аннары яшь парны туганнар бер-бер артлы котлады. Котлаудар арасында кунаклар күңел ачтылар. Алып баручылар төрле кызыклы уеннар оештырдылар. Туганнардан соң яшьләрне дуслары котлады. Алар кызыклы җырлар җырладылар, шигырьләр сөйләделәр. Туйда артистлар да чыгыш ясады: ике кыз скрипкада уйнадылар, бер ир-ат романслар җырлады, ә бер егет фокуслар күрсәтте. Аларның чыгышлары бик кызыклы булды. Кунаклар да рәхәтләнеп биеделәр һәм җырладылар.

Ахырдан барлык кунаклар белән яшьләр урамга чыктылар һәм фейрверк карадылар.

8. Сорауларга җавап бирегез. Ответьте на вопросы.

Туйда кунаклар нишлиләр?

Кызны нинди бәйрәм белән котлыйлар?

Балаларга кайсы бәйрәм ошый?

Истә калдырыгыз! Запомните!

Исем фигыль + бәйлек (имя действия + послелог)

Ул килү белән ... (как только он пришёл, ...);

без кайту белән (как только мы вернулись, ...).

9. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Бәйрәмнән кайту белән, без телевизордан ... карадык. Дусларым килү белән, мин аларга ... турында сөйләрмен. ... турында белү белән, мин сиңа шалтыратырмын. Кунаклар килү белән, ... башларбыз. Әбием әйтү белән, мин ... барырмын. Сезнең белән сөйләшү белән,мин ... җавап бирермен.

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Яңа ел җиту белән, ... Миңа әйтү белән, ... Аңа шалтырату белән, ... Сез безгә килү белән, ... Аларны күрү белән, ... Әбиемә килү белән, ... Дустымны котлау белән, ...Укытучы килү белән, ... Кызлар керү белән, ... Апам кияүгә чыгу белән, ...

11. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Исәнме, Диләрә!
— Сәлам, Гөлшат!
— Диләрә, бу кемнең туенда?
— Бу — минем апамның туе.
— Кайчан булды?
— 30 нчы декабрьдә.
— Кайда?
— «Татар ашлары йорты» ресторанында.
— Кеше күп булдымы?
— Йөзгә якын.
— Бик матур фотолар!
— Рәхмәт!

12. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— ..., сәлам!

— ...!

— Син шундый матур! ... барасың?

— Туйга ... .

— Кем ...?

— Дустым ... туена.

— ... өйләнә?

— ... .

— Ә, алар бергә университетта ... . Шулаймы?

— ..., дөрес. Бер группада ... . Ярый, миннән дә ... әйт. Иң ... теләкләр яшьләргә.

— ... .

13. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) көне, кияүгә чыкты, җәй, апам, Алмазга.
2) теләделәр, кунаклар, яшьләргә, һәм, шатлык, бәхет.
3) көнемне, белән, дусларым, туган, бәйрәм иттем, бергә.
4) тула, әбиебезгә, яшь, туксан, быел.
5) туган, әнинең, бәйрәм иттек, көнен, кафеда, яңа.

14. Туй фотосын күрсәтегез һәм аның турында сөйләгез.
Покажите фотографию свадьбы и расскажите о ней.

15. Яңа сүзләр төзеп әйтегез һәм тәрҗемә итегез. Образуйте новые слова и переведите их.

Бәйрәм — ..., дуслар — ..., заман — ...,
яшьләр — ..., шәһәр — ... .

-ча/-чә

Истә калдырыгыз! Запомните!
Исем фигыль + бәйлек (имя действия + послелог)

Сезне котлау өчен ... (чтобы поздравить вас, ...);
бәйрәм итү өчен ... (для того, чтобы праздновать ...).

16. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген кыскача сөйләгез.
Прочитайте текст и перескажите кратко его содержание.

Дусларымның исемнәре — Айрат, Зөлфия, Салават һәм Алия. Ә мин Тимур булам. Кичә без, Айратның туган көнен бәйрәм итү өчен, кичке алтыда кафеда җыелдык. Дустыбызны котлау өчен, башта сүзне Салаватка бирдек. Ул матур-матур сүзләр әйтергә бик оста, чөнки театр училищесында укый. Салават дустыбызга укуда уңышлар, яхшы сәламәтлек, күңелле сәяхәтләр теләде. Аннары Алия үзенең матур теләкләрен әйтте. Соңыннан без зөлфия белән Айратны котладык. Без дә аңа матур теләкләр теләдек, бигрәк тә спортта уңышлар. Айрат барлык теләкләргә дә шатланды, рәхмәт әйтте. Без ашадык, эчтек, аннары боулинг уйнарга киттек. Бәйрәмнән соң без саубуллаштык, бер-беребезгә хәерле юллар теләдек.

17. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Прочитайте выразительно стихотворение.

Әтием бар,
Әнием бар,
Ике апам.
Әниемнең
Әнисен дә
бик яратам.
Ә без аның
Оныклары
Өчәү инде.
Шулай булгач,
Без барыбыз
Ничәү инде?

Хакимҗан Халиков

18. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Куда вы идете сегодня вечером?
2) Когда состоится свадьба твоего брата?
3) Какие семейные праздники тебе нравятся?
4) Вам нравится невеста моего друга?
5) Что тебе подарили друзья на день рождения?
6) Где ты любишь отмечать свой день рождения?
7) Почему вы не были вчера на семейном празднике?
8) Сколько лет твоей бабушке? Вы празднуете ее день рождения?
9) Когда они переезжают в новую квартиру? Будут ли отмечать новоселье?
10) Кого Вы хотите поздравить с Новым годом? Что Вы хотите подарить?

19. Кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставляя нужные слова.

1) Дусларыбызның туенда кунаклар ... .
2) Ул бер кыз белән танышкан һәм аңа ... .
3) Миңа «Бүләкләр» кибетенә барырга ..., чөнки иртәгә апамның ... .
4) Абыемның гаиләсе яңа фатир алды, аларны ... белән ... барабыз.
5) Бу чибәр кыз — минем ... .

20. Сүзләр белән җөмләләр төзеп языгыз. Составьте и запишите предложения со словами.

Бәйрәм, котларга, бүләк итәргә, туган көн, өй туе, туй, табын.

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1) Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Ул дусты... тимераяк бүләк итәргә тели.

1) -ның 2) -на 3) -н

Алар «Татарстан» рестораны... булдылар.

1) -да 2) -ны 3) -нда

Без әбиебез... юбилее белән котладык.

1) -нең 2) -не 3) -гә

Мин кара чәчле, соры күзле кыз... гашыйк булдым.

1) -га 2) -ны 3) -ның

Бу ханымның кызы кияү... чыга.

1) -дә 2) -нең 3) -гә

Туганнарыбыз яңа фатир... күчәләр, һәм без аларны котларга барабыз.

1) -га 2) -ның 3) -да

Апамның кыз... туды, без аны котларга бардык.

1) -ны 2) -ы 3) -сы

2) Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставляя нужные окончания.

Кичә без туй... бардык. Туй мәҗлесе сәгать алты... башланды. Яшь гаилә... кер юу машинасы бүләк иттек. Кунаклар бәйрәм... күңел ачтылар, җырладылар, биеделәр. Быел әбиебезнең юбиле... була, аңа 90 яшь тула. Мин гаилә бәйрәмнәре... булырга яратам.

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.

Гаилә бәйрәмнәрегез турында сөйләгез.



ЯЛ ИТҮ УРЫННАРЫ. МЕСТА ОТДЫХА

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Җәй башланды. Укучылар, студентлар ял итәләр. Алар спорт лагерьларена, диңгезгә, тауларга баралар.

Җәйге ял бик күңелле уза. Без башка шәһәрләргә, илләргә барабыз, тарихи урыннар белән танышабыз.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Динар, җәен син кайда ял итәргә яратасың?
— Төркиягә барырга яратам.
— Дусларың беләнме?
— Әйе, дусларым белән дә, гаиләм белән дә.
— Төркиядә сиңа нәрсәләр ошый?
— Диңгез, табигать, борынгы истәлекләр.
— Миңа да анда ошый.

3. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз. Прослушайте, повторите и запомните.

диңгез – море
тау – гора
елга – река

кызынырга – загорать
йөзәргә – плавать
җәяү йөрергә – ходить пешком

күл – озеро
чүл – пустыня
утрау – остров

борынгы – старинный
искиткеч – удивительный

4. Үрнәк буенча диалог төзегез. Составьте диалог по образцу.

— Хәерле көн, балалар! Бүген без сезнең белән Казан Кремле буйлап йөрербез, тарихи урыннарны карарбыз. Менә бу ак манарага карагыз әле.

— Сөембикә манарасымы?

— Юк. Бу Спас манарасы. Аңа сәгать куелган.

— Ә Сөембикә манарасы кайда?

— Әнә тегендә, күрәсезме? Ул кызыл кирпечтән ясалган.

— Әйтегез әле, ул ничә катлы?

— Җиде катлы.

— Аның биеклеге ничә метр?

— 52 метр.

5. Үрнәк буенча әйтегез. Скажите по образцу.

Бу — Казан Кремле. Ул бик борынгы. Анда Кол Шәриф мәчете, Благовещение соборы, «Хәзинә» сәнгать галереясы, Президент сарае урнашкан.

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Иртәгә Без Болгарга экскурсиягә барабыз.
...? Кичә алар Казан Кремлендә булганнар.
...? Кичләрен ул Казан урамнары буйлап йөрергә ярата.
...? Башкалабызда тарихи урыннар күп.
...? Казанның Ирек мәйданында Пушкин белән Тукайга һәйкәл куелган.
...? Минем Милли музейны карыйсым килә.
...? Әбиемә Сөембикә манарасы бик ошый.
...? Бу — данлыклы Казан университеты.

7. Текстны укыгыз һәм үрнәк буенча дустыгыз турында сөйләгез.
Прочитайте текст и расскажите о друге (подруге) по образцу.

Бу — Илһам. Ул Казан университетында Физика институтында укый. Илһам — беренче курс студенты. Ул кечкенәдән астрономия белән кызыксына, бөтен вакытын йолдызлар өйрәнүгә багышлый. Шуңа күрә дә, мәктәптә укыганда ук, ул Халыкара һәм Бөтенроссия олимпиадаларында җиңүче булган. Аны хәтта Америкага укырга чакырганнар, ләкин ул туган шәһәрендә калган. Университетта уку аңа бик ошый. Буш вакытын да файдалы үткәрергә тырыша: кызыклы китаплар укый, дуслары белән дә аралаша, әти-әнисенә дә булыша, авылга әбисе белән бабасына да кайтырга онытмый.

8. Сорауларга җавап бирегез. Ответьте на вопросы.

Малай җәен нишләргә ярата?
Кыз кичләрен нишли?
Бабай нәрсәләр укый?

Истә калдырыгыз! Запомните!

Я ... я, яки, яисә (или); **әле ... әле** (то ... то) —
бүлүче теркәгечләр (разделительные союзы).

9. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Шәһәребездә күңел ачу ... күп. Иртәгә без апам белән я «Тандем» сәүдә-күңел ачу ..., я «Мега» ... барырбыз. Безнең иң яраткан ял итү урыныбыз ... . Дустымның Төркиягә яки Мисырга ... . Абыем ... белән шөгыльләнә, шуңа күрә тауларны ярата. Я сез безгә ..., я без сезгә ... . Җәен ... бармакчы буласыз? Быел җәен я ... ял итәрбез, я ... кайтырбыз. Якшәмбе көнне минем ... барасым килә.

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Дустымның я чит илгә барасы килә, я ... . Күңелле ял иту өчен, ... Минем дусларым белән ... . Иртәгә я музейга барырбыз, я ... . Буш вакытында я ул миңа килер, я ... . Быел Алсуның абыйсы я тауларга ... . Әниемнең әнисе авылда яши, шуңа күрә без ... . Авылга кайту белән, ул ... . Я Казан Кремленә барыгыз, я ... . Әле алар «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә концерт карыйлар, әле ... .

11. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Альбина, сәлам!

— Сәлам, Җәүдәт!

— Хәлләр яхшымы?

— Яхшы, рәхмәт.

— Җәен кайда ял итмәкче буласың?

— Спорт лагерена барам.

— Кайсы айда?

— Июльдә.

— Тагын кемнәр бара синең белән?

— Биш кеше барабыз.

— Ярый, яхшы ял сезнең барыгызга да.

— Рәхмәт, Җәүдәт.

12. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— О-о-о-о, бу нинди фото? Син монда кем ...?

— Бу минем яңа дустым — ... .

— Кайда ... ?

— Җәен мин ... булдым. Шунда таныштык.

— Кызык! Минемчә, ул бик ... .

— Әйе. Ул ... буйлы, ... чәчәле, ... күзле. Мин аңа бер күрүдә ... .

— Котлыйм! Ул ... укый?

— ... .

— ... курста?

— ... .

13. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) таулар, илдә, елгалар, биек, бар, диңгезләр, зур, безнең.
2) Авылда, яраталар, ял итәргә, дусларым, җәен.
3) Һәм, ошый, кайда, сиңа, ял итү, ни өчен?
4) күпме, урыннары, шәһәрегездә, ял итү?
5) өчен, ял итү, балаларга, бар, паркы, «Кырлай».

14. Шәһәрегезнең (авылыгызның) ял итү урыннары турында сөйләгез.
Расскажите о местах отдыха в вашем городе (селе).

15. Яңа сүзләр төзеп әйтегез һәм тәрҗемә итегез. Образуйте новые слова и переведите их.

Сәяхәт — ..., сәфәр — ..., юл — ..., урман — ..., умарта — ..., диңгез — ... .

-чы/-че

Истә калдырыгыз! Запомните!

Фигыльнең кайтым юнәлеше (возвратный залог глагола)

Ки — киенә (одевается), **ю — юына** (умывается), **бизә — бизәнә** (наряжается), **макта — мактана** (хвастается).

16. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген кыскача сөйләгез.
Прочитайте текст и перескажите его содержание.

Кышын ял көннәрендә Фәрит саф һавада йөрергә ярата. Ул җылы итеп киенә һәм урамга чыга. Урам буйлап әкрен генә бара, туган шәһәренең матурлыгына соклана. Фәритләрнең өеннән ерак түгел Универсиада авылы урнашкан. Бу — студентлар кампусы. Ул 2010 нчы елда төзелгән. 2013 нче елда Казанда XXVII Бөтендөнья Җәйге Универсиада үткәрелде. Әлеге спорт бәйрәменә төрле илләрдән спортчылар һәм делегацияләр килде. Алар Универсиада авылында яшәделәр. Анда 28 корылма бар. Торак йортлардан тыш, медиацентр, Теннис академиясе, «Буревестник» спорт комплексы, сәүдә үзәге, медицина комплексы, поликлиника, даруханә, ашханә, элемтә бүлеге һ.б. Хәзерге вакытта биредә 14 меңнән артык кеше яши. Алар арасында Казан университеты, IT лицей, Идел буе Спорт академиясе студентлары яши. Алар өчен барлык уңайлыклар бар.

17. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Прочитайте выразительно стихотворение.

Каникул

Кайчан килгән икән ул?
Кайчан киткән икән ул?
Рәхәт тә бит каникул,
Бигрәк кыска икән шул!

Резеда Вәлиева

18. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Где вы любите отдыхать летом?
2) Какие памятные места Казани тебе нравятся?
3) Как ты отдыхаешь зимой?
4) Вы были в татарском театре?
5) Тебе нравится отдыхать на море?
6) Как называется этот культурно-развлекательный центр?
7) Почему вы хотите отдыхать в Италии?
8) Вы были в Париже? Что вам понравилось больше всего?
9) Знакомы ли вы с достопримечательностями Москвы?
10) Что вы хотите посмотреть в нашем городе?

19. Кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставляя нужные слова.

1) Аның я ... ял итәсе килә, я авылда ....
2) Дустым саф һавада ... ярата.
3) Миңа башкалабызның ... бик ошый.
4) Минем апам йөзү белән ..., шуңа күрә ул ... ял итәргә ярата.
5) Бу тарихи ... булу өчен, ... кирәк.

20. Сүзләр белән җөмләләр төзеп языгыз. Составьте и запишите предложения со словами.

Ял, елга, диңгез, урман, тау, ил, шәһәр, истәлекле урыннар, авыл, ял йорты.

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Ул бу ял парк... булмаган әле.
1) -тан 2) -та 3) -ка

Алар Кара диңгез... ял иткәннәр.
1) -гә 2) -дән 3) -дә

Безнең истәлекле урыннар... буласыбыз килә.
1) -да 2) -га 3) -ны

Минем Париж... күрәсем килә.
1) -га 2) -да 3) -ны

Дусларыбыз җәй көне Кытай... булганнар.
1) -га 2) -да 3) -дан

Безнең авыл... ерак түгел биек тау бар.
1) -да 2) -ның 3) -дан

Мәскәү... зоопаркы туристларга бик ошады.
1) -не 2) -нең 3) -дән

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставляя нужные окончания.

Дусларыбыз... Африкага барасылары килә. «Кырлай» паркы... балалар да, олылар да рәхәтләнеп ял итәләр. Яхшы ял итү өчен, алар авыл... кайтмакчы булалар. Ул беркайчан да чил ил... булмаган әле. Кызлар я спорт лагере..., я ял йорты... бармакчы булалар. Авыл... кайту белән, мин күл... балык тотарга китәм.

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.
Яраткан ял итү урыннарыгыз турында сөйләгез.

ДУСЛАР БЕЛӘН АРАЛАШУ. ОБЩЕНИЕ С ДРУЗЬЯМИ.

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Бу – минем дустым Филүс. Дустыма ундүрт яшь. Ул Мәскәүдә яши, анда татар мәктәбендә укый.

Мин дустымны еш күрмим, ләкин без Интернет аша аралашабыз. Бүген дә дустымнан электрон хат алдым.

Дустымда төрле энциклопедияләр, кызыклы китаплар бар.

Дустымның туганнары күп.

2. Диалогларны тыңлагыз һәм укыгыз.
Прослушайте диалоги и прочитайте.

— Гүзәл, дусларың белән син ничек аралашасың?
— Хатлар язам, телефоннан шалтыратам, «Скайп» аша сөйләшәм.
— Сез еш күрешәсезме?
— Кызганычка каршы, еш түгел.

***

— Сәлам, Мансур!
— Сәлам, Артур!
— Бүген кинога барабызмы?
— Әйе, барырбыз. Син Маратны да чакырдыңмы?
— Әйе, чакырдым. Ләкин ул дустының туган көне бәйрәменә бара.
— Бик кызганыч, аның белән күңеллерәк булыр иде.

3. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз. Прослушайте, повторите и запомните.

кызганычка каршы – **к сожалению**
кызганыч – **жаль (жалко)**

күрешергә – **видеться**
язышырга – **переписываться**
аралашырга – **общаться**

имтихан – **экзамен**
арырга – **уставать**
уңышлар сиңа! – **успехов тебе!**

чакыру – **приглашение**
чакырырга – **приглашать**
каршы (түгел) – **(не)против**
машина узышы – **автогонка**

Истә калдырыгыз! Запомните!

Тартымлы исемнәрнең килешләрдә төрләнеше.

Склонение имен существительных с аффиксами принадлежности

дустым — мой друг (моя подруга)

дустымның — моего друга (моей подруги)

дустыма — моему другу (моей подруге)

дустымны — моего друга (мою подругу)

дустымнан — (от, с) моего друга (моей подруги)

дустымда — (в) моём друге (моей подруге); (у) моего друга (моей подруги)

4. Үрнәк буенча дусларыгыз белән аралашу турында әйтегез.
Скажите об общении с друзьями по образцу.

Минем дусларым күп. Филүсә белән без бер сыйныфта укыйбыз. Без һәр көнне очрашабыз, кичәләргә бергә йөрибез. Тагын бер дустым бар. Ул — Галия. Галия Түбән Камада яши. Без аның белән телефоннан сөйләшәбез, Интернет аша хатлар язышабыз. Камәр дә — безнең дустыбыз. Ул — төрек кызы. Без җәйге ял вакытында таныштык. Ул Төркиядә яши һәм укый. Без аның белән электрон хатлар язышабыз, «Скайп» аша аралашабыз.

5. Җөмләрәне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Бу — дустым ... . Ул ... яши. Без аның белән ... аралашабыз. Без ... турында сөйләшергә яратабыз.

Бу — Алсуның дусты. Аның исеме — ... . Алсуның дусты ... яши. Алар ... аралашалар. Алар ... турында сөйләшәләр.

Бу — әтиемнең дусты ... . Ул ... яши. Алар әтием белән ... сөйләшәләр, ... аралашалар. Ирек абый ..., ... ярата.

6. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Минем дусларым күп. Рүзәл — Казанда, Олег — Пензада, Азат — Мәскәүдә, Кодрәт — Пекинда, Азамат Аделаидада яши. Без спорт лагеренда таныштык. Без татарча көрәш белән шөгыльләнәбез. Дусларым белән еш очрашмыйбыз, ләкин «Скайп» аша сөйләшәбез, бер-беребезгә Интернет аша хатлар язабыз, телефоннан шалтыратабыз. Без дусларым белән татарча гына аралашабыз. Алар төрле шәһәрләрдә һәм илләрдә яшәсәләр дә, татарча беләләр, Татарстан һәм татарлар тормышы белән кызыксыналар. Дусларым Казанга килергә телиләр.

7. Дусларыгызның фотоларын күрсәтегез һәм алар белән ничек аралашуыгыз турында сөйләгез. Покажите фотографии друзей и расскажите, как вы с ними общаетесь.

Үрнәк: Бу — минем дусларым. Бер дустым ... .

8. Диалогларны укыгыз. Прочитайте диалоги.

— Сәлам, Илнур!

— Сәлам, Айнур!

— Бүген футбол карарга барабызмы?

— Әйдә, барабыз. Билетлар бармы?

— Әйе, минем өч билетым бар.

— Айдарны да чакырасыңмы?

— Мин аңа шалтыраттым инде. Ул бара. Мин сезне сәгать биштә көтәм.

— Шалтыратуың өчен рәхмәт, Айнур! Стадион янында очрашырбыз. Кичкә кадәр!

— Сау бул!

***

— Сәлам, Илүсә!

— Исәнме, Гөлназ!

— Хәлләрең яхшымы? Кичә нигә «Скайп»ка кермәдең?

— Яхшы, рәхмәт. Кичә дустымның туган көне иде. Без кафега бардык һәм аннан соң кайттык. Ә синең хәлләрең ничек? Нинди яңалыкларың бар?

— Ярыйсы, рәхмәт. Иртәгә имтихан була. Бүген күп укыдым, арыдым. Хәзер йокларга ятам. Иртә торасым бар.

— Уңышлар сиңа! Сау бул! Тыныч йокы!

— Рәхмәт! Сау бул!

***

— Хәлләрең ничек, Гүзәл? Балаларың исән-саумы?

— Рәхмәт, Рәзинә, бик яхшы. Ә син нихәл? Иреңнең хәлләре ничек?

— Барысы да яхшы, рәхмәт. Гүзәл, кафега чакыруыңа рәхмәт! Күптән очрашканыбыз юк иде.

— Әйе, минем дә очрашасым килде. Рәзинә, әйдә иртәгә гаиләләребез белән театрга барабыз.

— Ярар, мин каршы түгел. Билетлар бармы?

— Әйе, бар.

9. Диалогларны тулыландырыгыз. Дополните диалоги.

— ..., дустым!

— ...!

— Хәлләрең ...? Бүген кич ... барабызмы?

— Рәхмәт, ... Ярар, ... Сәгать ничәдә ... ? Кайда ... ?

— Сәгать ... көтәм.

— ... кадәр! Шалтыратуың өчен ... .

***

— Хәлләрең ничек, ...?

— ... Ә син нихәл?

— Рәхмәт, ... Гаиләң ... ?

— ... .

— Синең гаиләң дә ... ? Нинди ... бар?

— Барысы да ... . юк.

10. Сорауга җавап бирегез. Ответьте на вопрос.

Дуслар нишлиләр?

11. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Артур — минем иң якын дустым. Ул бик акыллы, юмарт, батыр кеше. Без күп аралашабыз. Бергә мәктәпкә барабыз, кичләрен саф һавада йөрибез, футбол уйныйбыз. Ял көннәрендә кинотеатрларга, спорт залына, стадионга йөрергә яратабыз.

Алия апа — апамның якын дусты. Ул тыйнак, ярдәмчел кыз. Алар апам белән еш күрешмиләр, ләкин аралашалар: телефоннан шалтыратышалар, Интернет аша хатлар язалар, «Скайп» аша сөйләшәләр.

Азат абый — әтиемнең дусты. Ул бик кызык, акыллы, ярдәмчел. Алар бергә эшлиләр, хоккей, машина узышлары карарга да бергә баралар. Без Азат абыйның гаиләсен дә беләбез, алар безне беләләр. Бер-беребезгә кунакка йөрибез.

12. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Иң якын дустымның исеме — ... . Без ... . Ул ... .

Апамның (абыемның, сеңлемнең, энемнең) иң якын дусты — ... . Алар ... . Алар бергә ... .

Әтиемнең (әниемнең) якын дусты — ... . Алар ... . Бергә ... . Без аның гаиләсен ... . Алар ... .

13. Сорауларга җавап бирегез. Ответьте на вопросы.

А) Дусларың күпме? Иң якын дустың кем? Сез ничек аралашасыз? Сез нәрсәләр турында сөйләшергә яратасыз? Дустыңның гаиләсен беләсеңме?

Ә) Сезнең гаилә дусларыгыз бармы? Алар нинди кешеләр? Сез алар белән еш очрашасызмы? Сез кайда очрашасыз? Сез кемгә кунакка йөрисез?

14. Татар мәкальләрен укыгыз һәм истә калдырыгыз.
Прочитайте и запомните татарские пословицы.

* Дус — дусының көзгесе. (Друг — зеркало друга.)
* Дусны табу җиңел, саклавы — авыр. (Найти друга легко, сберечь — сложно.)

15. Иң якын дустыгыз белән ничек аралашуыгыз турында сөйләгез.
Расскажите о том, как вы общаетесь с самым близким(ой) другом (подругой).

Иң якын дустымның исеме — ... . Ул ... (Татарстаннан, Украинадан, Төркиядән, Үзбәкстаннан). Дустым бик ... (акыллы, юмарт, ярдәмчел, кызык) кеше. Без аның белән ... (еш, сирәк) күрешәбез. Дустым белән ... (һәр көн, атна саен, кичләрен, дәресләрдән соң, ...), ... (телефоннан, Интернет аша, урамда, мәктәптә...) аралашабыз. Без бергә ... (кинога, футболга, китапханәгә, театрга, концертка, ...) йөрибез, ... (яңа китаплар, мода, машиналар, компьютер, ...) турында сөйләшергә яратабыз.

16. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Дустыбыз — бик яхшы кеше.
Дустыбызның энесе икенче сыйныфта укый.
Дустыбыздан хат алдык.
Дустыбызны кунакка чакырдык.
Дустыбызга унҗиде яшь тулды.
Дустыбызда бер атна кунакта булдык.

17. Диалогларны укыгыз. Прочитайте диалоги.

— Алия, синең дусларың күпме?
— Әйе, бик күп.
— Сез ничек аралашасыз?
— Телефоннан сөйләшәбез, Интернет аша хатлар язышабыз.

***

— Гүзәл, гаилә дусларыгызны туган көнеңә чакырдыңмы?
— Әйе. Сәгать бишкә алар да киләчәкләр.
— Бәйрәмдә ничә кеше булачакбыз?
— Егерме.

***

— Фәнүзә ханым, гафу итегез, Сез Әнәс әфәндегә хат яздыгызмы?
— Юк, мин аңа кесә телефоныннан шалтыраттым.
— Ул бәйрәмгә килерме?
— Әлбәттә, без — дуслар бит!

кесә телефоны – сотовый телефон

18. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Прочитайте выразительно стихотворение.

Дуслык балы

Дустым миңа алып килгән
Күчтәнәчкә «Башкорт балы»,
Янәшәгә мин дә куям —
Җыйган татар бал кортлары.
Гәрәбәдәй якты икән,
Икесе дә татлы икән:

Синең бал да кәттә икән,
Минем бал да яхшы икән!..
...Бозылмый да, картаймый да
Безнең татар-башкорт балы —
Гәрәбәдәй якты булсын,
Мәңге булсын дуслык балы!

Шәүкәт Галиев

19. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Наши друзья — весёлые люди.
2) Старший брат моей подруги учится в университете.
3) Мы общаемся с друзьями по «Скайп».
4) Сейчас я напишу письмо своему другу в Москву.
5) Алсу звонит своей подруге.
6) Вчера мы с моим другом ходили в татарский театр.
7) Моему другу нравятся водные виды спорта.
8) Мои друзья любят читать книги по истории татарского народа.
9) Подруга моего брата ездила в Англию.
10) Сегодня у моей лучшей подруги день рождения.

20. Дөрес языгыз. Напишите правильно.

Без бер-беребезгә хатлар яз... .
Кичен мин дусларым белән аралаш.... .
Ярый, Алсу, иртәгә шалтырат.... .
Дустым, дәресләрдән соң кафе янында очраш... .

21. Сүзләр белән җөмләләр төзеп языгыз. Составьте и запишите предложения со словами.

Кич белән, иртән, көндез, укудан соң, эшкә кадәр.

☑ ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ! ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Без Интернет ... аралашабыз.

1) аша 2) белән 3) кебек

Дустыгыз... кафеда күрдек.

1) -га 2) -ны 3) -дан

Туганнар... — бик яхшы кешеләр.

1) -ына 2) -еннән 3) -ым

Әтиемнең дусты... урамда күрдем.

1) -ннан 2) -на 3) -н

Туган көн... дусларымны чакырдым.

1) -емә 2) -емне 3) -емнең

Бу уенны апам... алдым.

1) -да 2) -нан 3) -ны

Аңа бу билетлар... әти-әнисе бирде.

1) -ны 2) -га 3) -дан

Мин аңа кесә телефоны... шалтыраттым.

1) -нан 2) -дан 3) -ннан

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, используя нужные окончания.

Без дусларым белән телефон... еш аралашабыз. Гадәттә, кичке сәгать сигездән соң миңа Алсу шалтырат... . Кичә Саша белән Марина кино... барганнар. Апамның дус... хәзер Италиядә яши. Дус... чаңгы ярышында беренче урынны алды. Бүген Сергей дуслар... кунакка бара.

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.

Чит шәһәрдә яшәүче дустыгыз турында сөйләгез.

ЯҢА КЕШЕЛӘР БЕЛӘН ТАНЫШУ. ЗНАКОМСТВО С НОВЫМИ ЛЮДЬМИ

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Без дустым белән Интернет аша таныштык.

Мин Марат белән спорт лагерендә таныштым.

Салих әфәнде бүген Кытайдан килгән татарлар белән танышкан.

Безнең төркемгә яңа студент килде. Без аның белән аудиториядә таныштык.

Әбием белән бабам госпитальдә танышканнар.

Әнием, сез әти белән ничек таныштыгыз?

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Салих, син Мансурны күптән беләсеңме?

— Ике ел беләм.

— Сез кайда таныштыгыз?

— Спорт лагерендә.

— Азат белән дә шунда очраштыгызмы?

— Әйе, без бер бүлмәдә яшәдек.

— Мансур белән Азат та танышлармы?

— Әйе, без бер командада футбол уйнадык.

3. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз. Прослушайте, повторите и запомните.

танышырга – знакомиться
таныштырырга – знакомить

киңәш итәргә – советовать
очратырга – встретить

аралашырга – общаться
шалтыратырга – звонить
очрашырга – встречаться

әңгәмәдәш – собеседник
кисәтергә – предупредить
күрешергә – повидаться

4. Үрнәк буенча диалог төзегез. Составьте диалог по образцу.

— Сәлам, Гүзәл!
— Сәлам, Әнисә!
— Таныш бул, Гүзәл, бу — Әминә. Әминә, бу — дустым Гүзәл.
— Мин бик шат, Гүзәл.
— Мин дә, Әминә. Әнисә, таныштыруың өчен зур рәхмәт.
— Кызлар, сез аралашыгыз, мин соклар алып киләм. Сезгә нинди сок ошый?
— Әнисә, син нинди сок алырга киңәш итәсең?
— Бу кафеда миңа алма согы бик ошый. Әминә, син алма согы яратасыңмы?
— Әйе, яратам.
— Әнисә, миңа чия согы күбрәк ошый. Аны алырга мөмкинме?
— Әлбәттә.

5. Үрнәк буенча дусларыгыз белән танышуыгыз турында әйтегез.
Скажите по образцу о знакомстве с друзьями.

Минем дусларым күп. Сергей белән без балалар бакчасында таныштык. Без аның белән бүгенге көнгә кадәр дуслар. Антон белән мине Сергей таныштырды. Ул — бик акыллы һәм тырыш егет. Без ял көннәрендә очрашабыз. Минем чит илдә дә дусларым бар. Али белән без Интернет аша таныштык. Ул Төркиядә яши. Хәзер аның белән хат һәм «Скайп» аша аралашабыз. Ул — кызыклы әңгәмәдәш. Джон америкалы. Без Казанда Универсиада вакытында таныштык. Ул — спортчы, волейбол уйный. Без бер-беребезгә электрон хатлар язышабыз. Дусларым — бик яхшы егетләр.

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Сергей мине дусты белән таныштырды.

...? Кичә без кафеда Маринаны очраттык.

...? Дустым Интернет аша аралашырга киңәш итте.

...? Азат чит ил студентлары белән танышкан.

...? Мин Саша белән телефоннан сөйләштем һәм без «Рәйхан» кафесында күрешергә булдык.

...? Фәрит — бик яхшы әңгәмәдәш.

...? Әбием безгә Илһам Шакиров концертына барырга киңәш итте.

...? Мин беләм: Интернет аша һәркем белән танышырга ярамый.

7. Текстны укыгыз һәм үрнәк буенча танышларыгыз турында сөйләгез. Прочитайте текст и расскажите о знакомых по образцу.

Минем танышларым күп. Мансур — спортчы. Без аның белән спорт лагерендә таныштык. Ул кышын — чаңгы шуарга, ә җәен велосипедта йөрергә ярата. Мансур хәзер тренер булып эшли.

Икенче дустым — Илдар. Без аның белән экскурсиядә таныштык. Ул — тарихчы. Илдар безгә Болгар һәм Биләр шәһәрләре турында кызыклы мәгълүматлар әйтте. Ул һөнәрен бик ярата. Бу мәгълүматлар безгә дә бик кызыклы булды.

Минем тагын бер дустым бар. Ул — Далер, Төрекмәнстаннан. Без аның белән Интернет аша таныштык. Далер компьютер программалары төзи. Ул бик акыллы. Без һәр көнне аның белән «Скайп» аша аралашабыз. Аның Казанга кунакка килгәне бар. Далер мине туганнан туган энесе белән таныштырды. Аның исеме — Ренат. Ул Казанда университетта укый, икътисадчы булырга тели. Ул миңа еш шалтырата. Ренат белән без телефоннан да аралашабыз, ял көннәрендә күрешәбез дә. Дуслар күп булу — бәхет ул.

8. Сорауларга җавап бирегез. Ответьте на вопросы.

Әни кем белән аралаша?

Кыз нишли?

Бабай балаларга нәрсәләр турында сөйли?

Истә калдырыгыз! Запомните!

Мөмкинлекне белдерә торган аналитик фигыльләрнең төрләнеше.

Спряжение аналитических глаголов, выражающих возможность

Барлыкта

В утвердительной форме

Мин таныша **алам**	Без таныша **алабыз**
Син таныша **аласың**	Сез таныша **аласыз**
Ул таныша **ала**	Алар таныша **алалар**

Юклыкта

В отрицательной форме

Мин таныша **алмыйм**	Без таныша **алмыйбыз**
Син таныша **алмыйсың**	Сез таныша **алмыйсыз**
Ул таныша **алмый**	Алар таныша **алмыйлар**

9. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

... бу мәгълүмат белән газетадан таныша алам. Кинотеатрда без ... белән таныша алабыз. Кышкы каникулда сез ... белән таныша аласыз. Син бу турыда ... таныша аласың. Алар ... белән таныша алалар. Ул Парижда ... белән таныша алмый. ... дустыма шалтырата алмыйм. Фәрит миңа Интернет аша .... ала. Без синең белән ... сөйләшә алмыйбыз.

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Мин дустыма кичен генә шалтырата алмыйм, чөнки ... . Ул тарих турында күп сөйли ала, шуңа күрә ... . Дустым озын хатлар яза ала, ләкин ... . Әбием сине Асия апа белән таныштыра ала, әмма ... . Алар безгә нинди ...? Иртәгә алар кайсы музейга ...? Бу турыда мин кайдан ... ? Дустым Америкага укырга китә алмый, аның .... . Укытучының телефонын без кемнән ... ? Кызлар кайда бию белән ... ? Малайлар шахмат ярышларында җиңүләре турында кемгә ... ?

11. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Алмаз, исәнме!

— Сәлам, Наил!

— Алмаз, Кремльгә кадәр кайсы автобус бара икән, син миңа әйтә аласыңмы?

— Кызганыч, әйтә алмыйм. Мин белмим. Әмма мин дустыма шалтырата алам. Минемчә, ул белә.

— Рәхмәт, кирәкми. Минемчә, без тукталышта белә алабыз. Анда язылган.

— Яхшы. Әйдә карыйбыз. Менә 89 нчы һәм 83 нче автобуслар белән бара аласың икән.

— Рәхмәт! 63 нче автобус һәм метро белән дә бара алам икән.

— Әйе шул. Син анда дустың белән очрашырга телисеңме?

— Әйе, чит илдән килгән дустым белән очрашам.

— Кремль — очрашу өчен бик матур урын. Сез анда музейга да керә аласыз, Кол Шәриф мәчетен һәм Благовещение соборын да күрә аласыз. Сезгә яхшы яллар телим!

— Рәхмәт, Алмаз!

12. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— Хәерле иртә, ...!

— ...! Без бүген укытучыбыз белән ... бармакчы булабыз.

— Сәгать ...?

— Нәрсә белән ...?

— Минемчә, ...

— Анда сәгать ничәгә кадәр ...?

— Көн буе. Сәгать ... кайтачакбыз.

— Ярый, хәерле юллар! Исән-сау йөрегез!

— ... .

13. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) Япониядәге, дустым, без, «Скайп», белән, аша, сөйләшәбез.
2) минем, белән, таныша аласыз, сез, Интернет, аша.
3) Салих, каникулда, Кытайга, дустына, бара ала, кышкы, кунакка.
4) егетләр, чаңгыда, шуа алалар, урманга, һәм, тимераякта, бара алалар, яки.
5) мин, еш, бик, урамда, транспортында, шәһәр, танышам.

14. Дусларыгыз белән сез ничек таныштыгыз? Шул турыда сөйләгез.
Как Вы познакомились со своими друзьями? Расскажите об этом.

15. Тәрҗемә итегез. Переведите.

Киләә алам — ...; укый алам — ...; белә алабыз — ...; сөйләшә алабыз — ...; шалтырата аласың — ...; таныштыра алалар — ...; кунакка килә аласыз — ... .

Истә калдырыгыз! Запомните!

Мөмкинлекне белдерә торган аналитик фигыльләрнең төрләнеше.

Спряжение аналитических глаголов, выражающих возможность

Барлыкта

В утвердительной форме

Мин ук**ый беләм**	Без ук**ый беләбез**
Син ук**ый беләсең**	Сез ук**ый беләсез**
Ул ук**ый белә**	Алар ук**ый беләләр**

Юклыкта

В отрицательной форме

Мин ук**ый белмим**	Без ук**ый белмибез**
Син ук**ый белмисең**	Сез ук**ый белмисез**
Ул ук**ый белми**	Алар ук**ый белмиләр**

16. Җөмләләрне укыгыз һәм тәрҗемә итегез. Прочитайте предложния и переведите их.

Мин фарсыча укый беләм һәм дустыма тәрҗемә итәргә ярдәм итәм. Ул, кызганычка каршы, гарәпчә укый белми, шуңа күрә ярдәм сорый. Син бу шигырьне сәнгатьле итеп укый беләсең. Без компьютер программаларын беләбез. Сез инглизчә укый беләсез, ә без юк. Алар кытайча укый белмиләр, ләкин өйрәнергә телиләр.

17. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Прочитайте выразительно стихотворение.

Без — кояш балалары
Туган якта куәт җыйгач,
Китәрбез әле ары.
Күзләр күктә: әйтерсең без
Очар кош балалары...

...Җирдә туып үссәк тә без,
Хыяллар гел югары.
Алсу битләр — ал кояштай,
Без — кояш балалары!

Разил Вәлиев

18. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1. Могу ли я тебе помочь?
2. Я могу с Вами познакомиться?
3. Ты сможешь прийти сегодня вечером в кафе?
4. Не могли бы Вы написать мне электронный адрес Азата?
5. Где Вы с ней познакомились?
6. Кто и когда Вас познакомил?
7. Вы можете мне сказать номер телефона вашего преподавателя?
8. Вы умеете читать по-китайски?
9. Они умеют работать на этом компьютере?
10. Смогу ли я доехать до Казанского цирка на 83-м автобусе?

19. Дөрес языгыз. Напишите правильно.

1) Сез бу автобуста Кремльгә бара... ?
2) Ул чит илдә яшәүче дустына хат яза... .
3) Без Интернет аша көн саен сөйләшә ал ....
4) Дустым мине сеңлесе белән таныштырма....
5) Алар гарәп графикасын укый бел ....

20. Сүзләр белән җөмләләр төзеп языгыз. Составьте и запишите предложения со словами.

Укый беләм, таныша аласың, яза белми, килә алалар, җырлый белә.

☑ ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ! ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Ул Төркиядәге дусты... хат язды.

1) -на 2) -ннан 3) -не

Алар дустының туган көнендә таныш...лар.

1) -ты 2) -ды 3) -те

Без спорт ярышларын телевизордан кар... алабыз.

1) -ый 2) -а 3) -арга

Мин гарәпчә яза бел...

1) -ергә 2) -де 3) -мим

Әтием әнием белән университет... танышкан.

1) -ка 2) -тан 3) -та

Дустымның апасы кытайча бик яхшы ук... белә.

1) -ый 2) -и 3) -ырга

Сез Бауман урамына кадәр метрода бар... аласыз.

1) -дыгыз 2) -а 3) -ырга

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, используя нужные окончания.

Алсу Америкадагы танышы белән Казан... танышкан. Ул кичә миңа шалтырат... алмады. Укучылар укытучы... электрон адресын белә алмадылар. Сезгә сәгать алтыга театр... барырга кирәк. Асия без... апасы белән таныштырды. Хәзер хатны сирәк язалар, СМСлар... еш җибәрәләр. Бүген мин спорт зал... бара алмыйм, гафу итегез. Син Казан университеты... кадәр бара беләсеңме?

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.
Дустыгыз белән танышуыгыз турында сөйләгез.



ТЕЛЛӘР ӨЙРӘНҮ. ИЗУЧЕНИЕ ЯЗЫКОВ

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Мин телләр өйрәнергә яратам. Туган телем — татар теле. Мин рус һәм инглиз телләрен беләм. Хәзер төрек һәм кытай телләрен өйрәнәм. Телләр белгән — илләр белгән, диләр. Минем чит илдә яшәүче дусларым да бар. Мин алар белән туган телләрендә сөйләшергә тырышам. Алар да миңа татар телендә хатлар язалар. Миннән татарча сөйләшергә өйрәнәләр.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Диләрә, син нинди телләр беләсең?
— Мин татарча, русча һәм инглизчә беләм.
— Тагын нинди чит телләр өйрәнергә телисең?
— Кытай һәм испанча өйрәнергә телим.
— Син инглиз телен кайда өйрәндең?
— Мәктәптә өйрәндем, аннары чит илдә тел өйрәнү курсларында булдым, анда практика үттем.
— Миңем дә инглиз телендә сөйләшәсем килә. Кызганычка каршы, мин инглизчә аңлыйм, укый алам, ләкин авыр сөйләшәм. Син миңа тел өйрәнү курсларының адресын бирмәссеңме?
— Әлбәттә. Анда барсаң, сөйләшергә тиз өйрәнерсең.
— Рәхмәт!

3. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз. Прослушайте, повторите и запомните.

туган тел – родной язык
чит тел – иностранный язык
чит ил – зарубежная страна

чит ил кешесе – иностранец
инглиз – англичанин, английский
төрек – турок (турчанка), турецкий

кытай – китаец (китаянка), китайский
татар – татарин (татарка), татарский
испан – испанец, испанский

үтәргә – пройти, проходить
аңларга – понимать
теркәлергә – регистрироваться
бик рәхәтләнеп – с удовольствием
тәрҗемәче – переводчик

4. Үрнәк буенча диалог төзегез. Составьте диалог по образцу.

— Дамир, син төрек телен Интернет аша өйрәнәсеңмени?

— Әйе, Камил. Монда чит телләр өйрәнү өчен күп төрле сайтлар бар. Мин төрек теле дәресләре булганын таптым.

— Син аны ничек өйрәнәсең?

— Онлайн мәктәптә теркәлү үттем, аннары күнегүләр эшләдем, язарга һәм укырга өйрәндем. Хәзер фильмнар карыйм, җырлар, шигырьләр өйрәнәм.

— Син укытучысыз өйрәнәсеңме?

— Укырга һәм язарга, грамматик кагыйдәләрне укытучысыз, үзем өйрәнәм. Ә укытучы белән виртуаль дәресләрендә дөрес сөйләшергә өйрәнәм.

— Телне үзең генә дә өйрәнеп буламыни?

— Хәзер була! Анда аудио- һәм видеоматериаллар күп, кагыйдәләр бик яхшы язылган. Сорауларны виртуаль дәресләрендә укытучыга биреп була. Теләсәң, син үзең дә өйрәнә аласың.

— Миңа бу сайтның адресын бир әле.

— Бик рәхәтләнеп!

5. Үрнәк буенча әйтегез. Скажите по образцу.

Мин русча һәм татарча беләм. Бу телләрдә яхшы сөйләшәм. Инглиз телен өйрәнәм. Тагын төрек һәм испан телләрен өйрәнергә телим. Минем чит телләрдә дә иркен аралаша аласым килә.

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Мин татар һәм рус телләрен беләм.
...? Мин инглиз телендә иркен аралашам.
...? Дустым чит телләр өйрәнергә тели.
...? Мансур төрек телен Интернет аша өйрәнә.
...? Фәритнең чит илдә дуслары бар.
...? Укытучыбыз безгә инглизчә сораулар бирә.
...? Без аңа чит телдә җавап бирәбез.
...? Телләр өйрәнү бик кызык.

7. Текстны укыгыз һәм үрнәк буенча дустыгыз турында сөйләгез.
Прочитайте текст и расскажите о друге (подруге) по образцу.

Бу — Гөлсем. Ул Казан университетында чит телләр өйрәнә. Гөлсем — татар кызы. Ул мәктәптә рус һәм инглиз телләрен өйрәнгән, университетта немец һәм испан телләрен өйрәнә башлаган. Гөлсемгә телләр өйрәнү бик ошый. Ул бик сәләтле кыз. Гөлсем европа телләрен дә, көнчыгыш телләрен дә белергә тели. Шуңа күрә ул төрек теле курсларына язылган. Хәзер бераз төрекчә дә сөйләшә ала. Ул кытайча һәм гарәпчә дә өйрәнергә хыяллана. Гөлсем буш вакытын файдалы үткәрергә тырыша: төрле телләрдә кызыклы китаплар укый, чит илдәге дуслары белән Интернет аша инглизчә, немецча аралаша. Ул туган телен дә онытмый, әти-әнисе һәм туганнары белән татарча гына сөйләшә.

Гөлсем тәрҗемәче булып эшләргә тели.

8. Сорауларга җавап бирегез. Ответьте на вопросы.



Бу китап нинди телдә язылган?
Кыз чит телне ничек өйрәнә?
Әби нинди телдә газета укый?

Истә калдырыгыз! Запомните!

Барысы, барлык (все), **бөтенесе** (всё), **үз** (сам), **һәммә** (все), **һәр** (каждый) — **билгеләү алмашлыклары** (определительные местоимения).

9. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Сыйныфыбызда барлык укучылар да ... сөйләшәләр. Мин барлык сүзләрне дә ... аңлыйм. Мансур ... үзе өйрәнергә теләде һәм курсларга язылды. Укучыларының һәммәсе дә .... яхшы сөйләшәләр, укый һәм яза беләләр. Сез үзегез безгә ... килегез. Без бөтенебез дә каникулларда ... барырга телибез. Барлык студентлар да ... телендә лекцияләр тыңлыйлар. Һәр укучының да яхшы ... аласы килә.

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Дустым бу турыда үзе ... . Мин, чит телләрне яхшы белү өчен, үзем ... . Ял көнелле үтсен өчен,барысы да ... . Мин барлык дусларым белән ... . Һәммәсе дә аңлашыла, ләкин ... . Буш вакытымда үзем чит тел ... . Быел Алсу үзе генә чит илгә ... . Мин барлык сүзләрне дә аңлыйм, ләкин ... . Авылга кайту белән, бөтен мәшәкатьләр ... . Без барыбыз да сине туган көнең белән ... . Бөтенегез дә мине игътибар белән ... . Һәр кеше дә ... булырга тели.

11. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Алия, сәлам!
— Сәлам, Җәмил!
— Алия, син барлык өй эшләрен дә эшләп бетердеңме?
— Әйе, Җәмил, барысын да.
— Мин бер сорауга җавап тапмадым. Ярдәм ит әле.
— Бик рәхәтләнеп. Сора.
— Менә бу сорау. Үзең укып кара әле.
— Әйе. Хәтерлим. Мин аңа җавапны Интернеттан таптым. Хәзер сиңа сайтның адресын бирәм.
— Рәхмәт, Алия. Син ничек барысына да өлгерәсең?

— Телләр өйрәнү миңа бик ошый. Барысы да җиңел бирелә. Каникулларда чит илгә барырга җыенам, шуңа күрә күп укыйм.

— Уңышлар телим, Алия.

— Рәхмәт, Җәмил.

12. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— Бу кемнең фотосы? ... кем сурәтләнгән?

— Бу ... Әлиф.

— Ул ...?

— Әлиф Германиядән. Ләкин ул — төрек ... . Ул Берлинда ... .

— Сез аның белән ... таныштыгыз?

— Без аның белән Интернет аша ... .

— Нинди ... сөйләштегез?

— Без татарча ... . Ул немецча, төрекчә, татарча һәм инглизчә яхшы ... . Рус телен ... тели.

— Ул татар телен ... өйрәнгән?

— 2010 нчы елда ул Казанга ... һәм анда татар теленә өйрәтү курсларында укыган.

— Аңа ... ошыймы?

— Минемчә, ...

13. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) дустым, чит, өйрәнә, институтта, телләр.
2) ул, өйрәнгән, үзе, Интернет, татар, аша, телен.
3) мин, яхшы, инглизчә, ләкин, аңлыйм, аз, сөйләшәм.
4) чит, нинди, телләр, өйрәнергә, син, телисең?
5) без, аралашабыз, иркен, рус, татар, һәм, телләрендә, инглиз.

14. Телләр өйрәнүегез турында сөйләгез. Расскажите о том, как Вы изучаете языки.

15. Яңа сүзләр төзеп әйтегез һәм тәрҗемә итегез. Образуйте новые слова и переведите их.

Татар — ..., инглиз — ..., төрек — ..., рус — ..., испан — ..., немец — ... .

-ча/-чә

Истә калдырыгыз! Запомните!

Бер — бердә (в час), **ике — икегә** (к двум), **өч — өчне** (три/трёх), **дүрт — дүрттән** (с четырех), **биш — биштә** (в пять).

Числительные могут изменяться по падежам.

16. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген кыскача сөйләгез.
Прочитайте текст и перескажите его содержание.

Сания чит телләр белән кызыксына. Ул институтта испан һәм гарәп телләрен өйрәнә. Һәр атнаның дүшәмбе, чәршәмбе һәм җомга көннәрендә сәгать уннан бергә кадәр ул испан теле өйрәнә. Сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм шимбәдә сәгать сигездән бергә кадәр институтта гарәп теле дәресләре була. Атнага ике тапкыр Сания инглиз теле курсларына укырга йөри. Курсларда дәресләр сәгать кичке алтыда башлана һәм сигездә тәмамлана.

Саниянең дуслары да күп. Алар арасында татарлар, руслар да, чит ил кешеләре дә бар. Дуслары белән Сания татарча, русча, испанча, гарәпчә сөйләшә. Курслардагы танышлары белән алар инглизчә аралашалар, бергә фильмнар карыйлар, инглиз җырлары һәм мәкальләре өйрәнәләр.

Сания һәр ел саен бер чит илгә барып кайтырга тырыша. Быел җәйге каникулларда ул Испаниягә барырга җыена. Анда яңа дуслар табарга, испан телендә күбрәк аралашырга, Испаниянең истәлекле урыннары белән танышырга тели. Хәзер ул Испания, аның халкы, испаннарның гореф-гадәтләре турында күп китаплар укый. Сания Интернет аша Испаниядә яшәүче дуслар да тапты. Алар «Скайп» аша еш аралашалар. Дуслары Саниянең сорауларына җавап бирәләр, үз илләре һәм телләре турында кызыклы мәгълүматлар сөйлиләр. Сания Испаниягә баргач, алар очрашырга җыеналар.

17. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Прочитайте выразительно стихотворение.

Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле, затлы тел...
Тел кешене дус итә,
Бер-берсенә беркетә.
Бел, балам, рус телен
Һәм онытма үз телең.

Шәйхи Маннур

18. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Где вы изучали иностранный язык?
2) Какие иностранные языки Вы знаете?
3) С кем Вы общаетесь на татарском языке?
4) Вы были за рубежом?
5) Тебе нравится изучать иностранный язык?
6) У тебя есть друг, живущий за рубежом?
7) Почему вы хотите изучать английский язык?
8) Все ли хотят пойти на курсы арабского языка?
9) Вы читаете книги на турецком языке?
10) Какой язык является твоим родным языком?

19. Кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставляя нужные слова.

1) Һәр кешең ... теле була.
2) Алар барысы да мәктәптә ... өйрәнгәннәр.
3) Мин һәр атнада чит илдәге дустымнан ... алам.
4) Чит тел өйрәнеп, ... онытырга ярамый.
5) Мин инглизчә аңлыйм, ләкин яхшы ... .

20. Сүзләр белән җөмләләр төзеп языгыз. Составьте и запишите предложения со словами.
Туган тел, чит тел, чит ил, чит ил кешесе, өчтән, бишкә, һәр, бөтен, барысы.

☑ ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ! ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Мин инглизчә мәктәп... өйрәндем.

1) -тән 2) -тә 3) -кә

Алар чит ил... киткәннәр.

1) -гә 2) -дән 3) -дә

Безнең испан теле курслар... языласыбыз килә.

1) -да 2) -га 3) -ына

Минем төрек тел... өйрәнәсем килә.

1) -гә 2) -не 3) -ен

Дусларыбыз Кытай... яшиләр.

1) -га 2) -да 3) -дан

Дәресләр... без татарча гына аралашабыз.

1) -дә 2) -гә 3) -дән

Мин китапларны рус теле... генә укыйм.

1) -ә 2) -ең 3) -ндә

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставляя нужные окончания.

Дусларыбыз... татар телен өйрәнәселәре килә. Инглиз теле курслар... балалар да, олылар да рәхәтләнеп йөриләр. Телне яхшы өйрәнү өчен, алар чит ил... китмәкче булалар. Ул һәр атнада җомга көнне өч... бишкә кадәр гарәп теле өйрәнә. Кызлар барысы да төрек... яхшы сөйләшәләр. Чит ил кешеләре... Казанны күрәселәре килә.

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.

Телләр өйрәнүегез турында сөйләгез.

ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

ТАТАР ТЕЛЕ. ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Татар теле — төрки телләрнең берсе.

Татар телендә сигез миллионга якын кеше сөйләшә.

Татар һәм рус телләре — Татарстан Республикасының дәүләт телләре.

Татар телендә сөйләшүчеләр Татарстанда гына түгел, Россиядә һәм чит илләрдә дә яшиләр.

Татар теле — матур, моңлы тел.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Самат, синең туган телең кайсы тел?

— Әлбәттә, татар теле. Ә синеке, Алина?

— Минеке — рус теле.

— Син татарча да бик яхшы сөйләшәсең бит. Кайда өйрәндең?

— Әйе, яхшы сөйләшәм. Мәктәптә беренче сыйныфтан унберенчегә кадәр татар теле дәресләре булды. Шунда өйрәндем.

— Алина, ә гаиләдә сез нинди телдә сөйләшәсез?

— Әти-әнием һәм бабам белән рус телендә, әбием белән татарча сөйләшәм.

— Шулаймыни?

— Әйе, ул — татар.

3. **Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз.** Прослушайте, повторите и запомните.

дәүләт теле – государственный язык
моңлы – мелодичный
төрки – тюркский

үтенеч – просьба
кагыйдә – правило
ярдәм – помощь

хөкүмәт – правительство
рәсми – официальный
төбәк – регион

кабат – еще раз
кардәш – родственный
үзлектән – самостоятельно

4. **Үрнәк буенча диалог төзегез.** Составьте диалог по образцу.



— Алло, сәлам, Галия!
— Сәлам, Мәдинә!
— Хәлләр ничек?
— Рәхмәт, әйбәт. Ә синеке ничек?
— Яхшы, рәхмәт. Галия, сиңа үтенечем бар иде, ярдәм итә алмассыңмы?
— Тыңлыйм, дустым, нинди ярдәм кирәк?
— Мин реферат язам, миңа татар теле турында мәгълүмат кирәк. Кайдан табарга мөмкин икән?
— Интернеттан таба аласың. Татарстан Республикасы хөкүмәтенең рәсми сайтында яки «Татар иле» сайтында күп мәгълүмат бирелгән. Кирәк булса, мин сиңа китаплар исемлеген дә хат белән язып җибәрә алам.
— Рәхмәт, дустым. Хәзер бу сайтларны карыйм. Аннан соң кабат шалтыратырмын.
— Яхшы.

5. Үрнәк буенча үзегез белгән телләр турында әйтегез.

Скажите о языках, о которых вы знаете, по образцу.

Татар теле — татар халкының туган теле. Ул төрки телләр гаиләсенә керә. Татар теле — башкорт, казах, кыргыз, кыпчак, төрек, үзбәк һәм башка телләр белән кардәш тел. Татар телендә сигез миллионга якын кеше сөйләшә. Бу телдә Татарстанда яшәүче татарлар гына түгел, Россиянең башка төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүчеләр дә бер-берсе белән аралаша. Татар теле Татарстан Республикасында рус теле белән бергә дәүләт теле булып исәпләнә.

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Татар телендә сөйләшүчеләр Татарстанда гына түгел, Россиянең башка төбәкләрендә һәм чит илләрдә дә яшиләр.

...? Татар теле мәктәпләрдә, университет һәм институтларда укытыла.

...? Кичләрен ул татар газеталарын укырга ярата.

...? Татар телендә балалар өчен күп газеталар чыга.

...? Татар теле төрки телләр гаиләсенә керә.

...? Без татар җырчылары концертына бардык.

...? Әбием минем белән татарча гына сөйләшә.

...? Кичләрен дустым татар теле өйрәнә.

7. Текстны укыгыз һәм үрнәк буенча дустыгыз турында сөйләгез.

Прочитайте текст и расскажите о друге (подруге) по образцу.

Мин — татар егете. Исемем — Илдус. Мин Кытайда тудым. Әти-әнием — татарлар, ләкин чит илдә үскәнгә, кызганычка каршы, мин татарча бик яхшы сөйләшмим. Мин барысын да аңлыйм, ләкин аз сөйләшәм. Хәзер мин «АНА ТЕЛЕ» онлайн мәктәбендә татар теле өйрәнәм. Андагы кагыйдәләр белән танышам, күнегүләр эшлим, укыйм һәм язам. Төркем дәресләрендә без күп сөйләшәбез. Мин укытучының сорауларына җавап бирәм, башка укучылар беләш аралашам. Дәресләрдә татар теле, татарлар һәм Татарстан Республикасы турында күп мәгълүматлар беләм.

Дәресләр турында Кытайдагы дусларыма да сөйләдем. Хәзер алар да татар теле өйрәнәләр. Безгә дәресләр бик ошый.

8. Сорауларга җавап бирегез. Ответьте на вопросы.

Малай нәрсә укый?
Сезнеңчә, кыз телефоннан кем белән сөйләшә?
Бабай кичләрен нишли?

Истә калдырыгыз! Запомните!

Ничәү? (Сколько?)

Берәү (один), **икәү** (вдвоём), **өчәү** (втроём), **дүртәү** (вчетвером), **бишәү** (впятером), **алтау** (вшестером), **җидәү** (всемером), **сигезәү** (восьмером), **тугызау** (вдевятером), **унау** (вдесятером) — **җыю саннары** (собирательные числительные).

9. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Алар ... җидәү килделәр. Җәйге каникулда без алтау ... бармакчы булабыз. Иртәгә алар икәү татар ... бара алалар. Кышкы каникулда сез өчәү ... ял итәсезме? Татар .... дәресенә алар унау килделәр. Сез безгә дүртәү ... киләсезме? Алар бишәү сезгә ... тәкъдим итмәкче булалар.

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Дусларым өчәү Казанга бармакчы булалар, чөнки ... . Без алтау Татарстан тарихы белән кызыксынабыз һәм ... . Алар бишәү татар телен өйрәнергә телиләр, ләкин ... . Якшәмбедә сез икәү кая ...? Алар дүртәү кайсы музейга ...? Без икәү әниемнең туган көненә ... . Америкадан өчәү укырга китмәкче була, ләкин алар ... . Салих белән дүртәү татарча сөйләшәләр һәм ... .

11. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Алмаз, сиңа бу фильм ошадымы?

— Әйе, Нияз! Ә сиңа?

— Миңа да ошады. Минем татарча фильмнар караганым юк иде әле. Бу беренче тапкыр каравым.

— Шулаймыни?! Ә мин татарча кинофильмнарны да карарга тырышам.

— Алмаз, сиңа бер үтенечем бар: икенче тапкыр тагын мине үзең белән алып бар әле. Минем татар телендә булган башка киноларны да карыйсым килә. Ярыймы?

— Әлбәттә, бик рәхәтләнеп! Киләсе атнада яңа фильм булачак. Шуңа барырбыз.

— Яхшы, икәү барырбыз. Кайсы кинотеатрда булачак?

— Кызганычка каршы, мин белмим әле. Белсәм, сиңа шалтыратырмын.

— Ярар. Мин дусларыма да әйтермен. Минемчә, татар телендә аларның да фильм караганнары юктыр әле.

— Ярар, әйт. Бергә барсак, күңеллерәк булыр.

12. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— Исәнмесез!

— ...! Безнең бүген татар теле дәресе... булачак?

— Сәгать ... .

— ... бүлмәдә?

— Минемчә, ...

— Без анда ...?

— Мин төгәл белмим, ләкин ... .

— Шулаймыни?! Мин һичшиксез киләм. Очрашканга кадәр!

— ... .

13. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) мин, элек, ике, өйрәнә, ел, татар, башладым, теле.

2) дәресләрендә, без, татар, җырлыйбыз, теле, җырлары, татар, өйрәнәбез, шигырьләр, тизәйткечләр, һәм.

3) татар, моңлы, тел, һәм матур, теле.

4) Америкадагы, өйрәнәләр, дусларым, теле, яратып, бик, татар.

5) әнием, татар, карый, генә, телендә, яңалыкларны.

14. Сез татар телендә ниләр эшлисез? Шул турында сөйләгез.
Что вы делаете на татарском языке? Расскажите об этом.



15. Яңа сүзләр төзеп әйтегез һәм тәрҗемә итегез. Образуйте новые слова и переведите их.

Спорт — ..., шахмат — ..., тел — ..., көрәш — ... .

-чы/-че

Истә калдырыгыз! Запомните!
Егермеләп (около двадцати), **кырыклап** (около сорока), **йөзләп** (около ста), **биш-алты** (пять-шесть), **өч-дүрт** (три-четыре) — **чама саннары** (приблизительные числительные).

16. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген кыскача сөйләгез.
Прочитайте текст и перескажите его содержание.

Без он-лайн режимда татар теле өйрәнәбез. Башта һәрберебез үзлегеннән күнегүләр эшли, кагыйдәләр белән таныша, укырга һәм язарга өйрәнә. Һәр темага егермеләп күнегү эшлибез, дәрес саен фильмнар карыйбыз, җырлар һәм шигырьләр тыңлыйбыз. Аннары без төркем дәресләрендә укытучы белән сөйләшәбез. Һәр дәрестә биш-алты кеше була. Без укытучының унлап соравына җавап бирәбез, үзебез дә сораулар бирәбез, бер-беребез белән аралашабыз. Татар теле дәресләрендә татарча гына сөйләшәбез. Бу дәресләр безне дөрес сөйләшергә, оялмаска өйрәтәләр. Алардан без Татарстан Республикасы, татар халкы һәм татар теле, Татарстанның истәлекле урыннары һәм табигате, хайваннар дөньясы һәм табигате турында күп мәгълүмат беләбез.

Дәресләрдән соң да дуслар белән татарча сөйләшәбез, хатлар язышабыз. Бу дәресләрдә өйрәнгән җырларны җырлыйбыз. Кайвакыт театр һәм концертларда очрашабыз, бергә кафеларга барабыз.

Татар теле дәресләре безне дуслаштыра.

17. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Прочитайте выразительно стихотворение.

Туган телем

Бик борынгыдан
Бабалар аша
Миңа да килеп җиттең.
Бирдең аң,
бирдең белем.
Хәзер инде
Офыктагы маяк булып,
Алга чакыр,
татар теле,
Тукай теле,
туган телем.

Акъегет

18. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Что вы знаете о татарском языке?
2) Где вы разговариваете на татарском языке?
3) Когда ты слушаешь татарские песни?
4) Вы часто бываете в татарском театре?
5) Какие песни на татарском языке ты знаешь?
6) Вы смотрели фильмы на татарском языке?
7) Почему ты не прочитал это произведение на татарском языке?
8) С кем вы любите общаться по-татарски?
9) Скажите, пожалуйста, у вас есть книги татарских авторов?
10) Что вы знаете об истории татарского народа?

19. Дөрес языгыз. Напишите правильно.

1) Мин татар телендә доклад сөйләмәкче була... .
2) Ул Болгарга бар... тели.
3) Без татарча гына аралаш... булабыз.
4) Дустым татар теле курсларына язып... тели.
5) Алар татар җырларын тыңла... яраталар.

20. Сүзләр белән җөмләләр төзеп языгыз. Составьте и запишите предложения со словами.

Үтенеч, рәсми, ярдәм, төбәк, аралашырга, игътибар итәргә, хөкүмәт.

☑ ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ! ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Ул татар теле... сөйләшмәкче була.
1) -ндә 2) -дә 3) -гә

Алар татар музыкасы фестивале... икәү килергә телиләр.
1) -дә 2) -нә 3) -ндә

Без татарча фильмнар... карарга яратабыз.
1) -ны 2) -да 3) -ын

Бу конкурс... һәр мәктәптән икешәр кеше катнашты.
1) -га 2) -та 3) -ка

Кайбер студентлар татарча китапларны китапханә... алалар.
1) -гә 2) -дә 3) -дән

Җәен балалар «Сәләт» лагере... татарча гына сөйләшкәннәр.
1) -нда 2) -ндә 3) -на

Без күп вакытыбыз... татарча сөйләшеп үткәрәбез.
1) -ны 2) -ын 3) -дан

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставляя нужные окончания.

Чит илдән килгән дустым Казан... булган. Ул татар операсы... бармакчы була. Укучылар татар теле дәресе... яңа сүзләр өйрәнделәр. Кызлар... татар җырлары бик ошый. Без алтау ара-тирә очраша... . Гафу итегез, татар театры... бүген нинди тамаша була? Бу язучы татар халк.... турында тарихи роман язган.

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.

Татар теле турында сөйләгез.

ТАТАР ДИАСПОРАЛАРЫ. ТАТАРСКИЕ ДИАСПОРЫ

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Татарлар Татарстанда гына түгел, Россиянең төрле төбәкләрендә дә, чит илләрдә дә яшиләр. Татарлар төрле елларда, төрле сәбәпләр аркасында чит илләргә киткәннәр. Хәзерге вакытта егерме биш меңгә якын татар Төркиядә яши. Татар диаспоралары Канадада да, Австралиядә дә бар.

Татар диаспоралары турында китаплар язалар.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Сәлимә, синең чит илләрдә яшәүче татарлар турында ишеткәнең бармы?

— Әйе, Төркиядә, Кытайда, Австралиядә яшәүче татарлар турында беләм. Алар башка илләрдә дә яшиләрме?

— Әйе, Финляндиядә, Литвада, Польшада, Германиядә һәм башка илләрдә дә яшиләр.

— Кызык, ләкин минем алар турында ишеткәнем юк иде.

3. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз. Прослушайте, повторите и запомните.

горефгадәт – традиция
сәбәп – причина
элемтә – связь

буын – поколение
дулкын – волна
язмыш – судьба

саклап калырга – сберечь
онытмаска – не забывать

4. Үрнәк буенча диалог төзегез. Составьте диалог по образцу.



— Дамир, сәлам!

— Сәлам, Әмир!

— Дамир, татар диаспоралары кайсы илләрдә бар? Әйт әле.

— Төркиядә, Кытайда, Германиядә, Америкада, Финляндиядә, Польшада, Австралиядә барын беләм.

— Мин Канадада да татарлар барын ишеттем. Бу дөресме икән?

— Дөрестер, Әмир. Татарларны язмыш төрле җирләргә җибәргән бит.

— Дамир, бүген «Мир» кинотеатрында татар диаспоралары турында фильм була. Барасың килмиме?

— Барасым килә, Әмир. Сәгать ничәдә?

— Дүрттә. Әйдә, бергә барабыз. Мин сине дүртенче яртыда тукталышта көтәрмен.

— Ярар, очрашканга кадәр сау бул!

— Сау бул!

5. Үрнәк буенча әйтегез. Скажите по образцу.

Татарлар Татарстанда гына яшәмиләр. Татар диаспоралары дөньяның төрле илләрендә дә бар. Алар бу илләргә төрле елларда, төрле сәбәпләр аркасында киткәннәр. Хәзер Татарстан Республикасы чит илләрдәге татарлар белән элемтәдә тора.

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Татарлар чит илләрдә дә яшиләр.

...? Чит илләргә татарлар төрле елларда һәм төрле сәбәпләр аркасында киткәннәр.

...? Чит илләрдәге татарлар телләрен саклап калырга тырышалар.
....? Австралиядә татарлар Сабантуй бәйрәмен зурлап үткәрәләр.
...? Чит илләрдәге татарлар Казанда еш булалар.
...? Татарстан хөкүмәте чит илләрдәге татарлар белән элемтәдә тора.
...? Татарлар чит илдә дә гореф-гадәтләрен сакларга тырышалар.
...? Татарлар милли ризыклар пешерәләр.

7. Текстны укыгыз һәм үрнәк буенча үзегез турында сөйләгез.
Прочитайте текст и расскажите о себе по образцу.

Бу — Әсма. Ул университетта укый. Әсма — татар кызы, ләкин ул Германиядә яши. Аның әбисе һәм бабасы Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң Германиядә яшәп калганнар. Әсма Берлинда туган, немец мәктәбендә укыган. Әсма татарча да бик яхшы сөйләшә. Гаиләләрендә татарча гына сөйләшәләр икән. Әсма татар бәйрәмнәрен белә, татар милли ризыкларын пешерә. Ул тәрҗемәче булырга тели, шуңа күрә телләр өйрәнә. Әсма немецча, төрекчә татарча, инглизчә иркенле сөйләшә. Ул испан һәм португал телләрен дә өйрәнә.

8. Сорауларга җавап бирегез. Ответьте на вопросы.

Малай кайсы илдән килгән?
Кыз кайсы илдә яши?
Бу әфәнде хәзер кайда яши?

Истә калдырыгыз! Запомните!

Килеп — придя; **яшәп** — живя; **кабатлап** — повторяя; **ярдәм итеп** — помогая.
-ып/-еп, -п — хәл фигыль формасы (форма деепричастия)

9. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Кабатлап әйтегезче, бу егет кайсы ...? Аңлатып китегезче, алар ни өчен ...? Сез боларны кайдан укып ... ? Алар Татарстан белән кызыксынып ... . Син кайда ... яратасың? Сез кайсы университетта ... ? Алар хат язып ... ? Синең ... барып кайтканың бармы?

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Алар иртән мин ... . Миңа татарча ... . Без Төркиягә ... . Укып бетергәч, ... Тыңлап утырдылар һәм ... . Миңа сәлам әйтеп, ... Татарча җырлар җырлап, ...

11. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Фирүзә, бу синме?

— Әйе, Халисә. Мин.

— Син ике атна элек кайда идең?

— Кытайда, Голҗа шәһәрендә. Кытайда яшәүче татарларда кунакта булдым.

— Сез нинди телдә сөйләштегез?

— Татарча. Алар татарча яхшы сөйләшәләр, телләрен һәм гореф-гадәтләрен саклап калганнар.

— Шулаймыни? Алар сине нәрсә белән сыйладылар?

— Бик тәмле ризыклар белән. Мин аларның исемнәрен хәтерләмим.

— Сиңа кунакта ошадымы?

— Әлбәттә. Алар — бик кунакчыл кешеләр.

12. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— Сәлам, дустым!

— ...!

— Әйдә, Төркиядән килгән татарлар белән очрашуга ... .

— Әлбәттә. Очрашу ... һәм ... була?

— Бүген сәгать ... .

— Очрашуга кемнәр ... ?

— Теләгән һәр кеше килә ала. Керү ирекле.

— ... .

13. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) чит, илләрдәге, саклап, татарлар, телләрен, калганнар.
2) онытып, алар, татар, бетермәгәннәр, җырларын.
3) кирәк, китаплар, татарча, аларга, дәреслекләр, һәм.
4) диаспоралары, татар, бергә, яшиләр, аралашып, хәбәрләшеп.
5) чит, татарлар, илләрдәге, милли, татар, ризыкларын, пешерәләр.

14. Фотога карагыз һәм Австралиядәге Сабан туе турында сөйләгез.
Посмотрите на фотографию и расскажите о Сабантуе в Австралии.

15. Яңа формалар төзеп әйтегез һәм тәрҗемә итегез.
Образуйте новые формы и переведите их.

-ып/-еп, -п

Җырла — ..., көл — ..., укы — ..., пешер — ..., яз — ..., уйла — ..., бел — ... .

Истә калдырыгыз! Запомните!
Бара-бара (идя), **укый-укый** (читая), **сөйләшә-сөйләшә** (разговаривая), **әйтә-әйтә** (говоря), **бии-бии** (танцуя) — **хәл фигыль формалары** (формы деепричастия).

16. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген кыскача сөйләгез.

Прочитайте текст и перескажите кратко его содержание.

Татарларның күпчелеге Татарстанда яши. Төрле елларда, төрле сәбәпләр белән чит илләргә киткән татарлар да бар. Татарлар Чиләбе, Оренбург, Пермь өлкәләрендә, Башкортстанда, Украинада, Молдова һәм Литвада, Эстониядә, Себердә һәм башка төбәкләрдә яшиләр. Төркиядә, Финляндиядә, Америкада, Кытайда һәм Австралиядә татар диаспоралары бик көчле.

Элек татар диаспораларының Казан, Татарстан белән элемтәләре булмаган. Әмма алар туган телләрен, диннәрен онытмаганнар, саклап калганнар, аларны буыннан-буынга тапшырганнар.

1990 нчы еллардан башлап, алар Татарстан белән тыгыз элемтәдә торалар. Татарстан Республикасы хөкүмәте аларга китаплар, мәдәни чаралар белән ярдәм итә, бәйрәмнәр оештырырга булыша.

Чит илләрдәге татарлар ел саен Сабантуй бәйрәмен зурлап үткәрәләр. Татарстанда уза торган корылтайга, халыкара ярышларга һәм бәйрәмнәргә киләләр. Татарстанлылар аларга телне өйрәтүдә, милли йола, гореф-гадәтләрне искә төшерүдә ярдәм күрсәтәләр. Аралар ерак булса да, тел бер, халык бер бит.

17. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз.

Прочитайте выразительно стихотворение.

Шундый туган як

Җәйләр яшел,
Кышлар ак.
Бездә шундый
Туган як.
Көзен сары,
Алтындай.
Янып торган
Ялкындай.
Ә нинди соң
Гөлле яз?
Аңа бөтен
Төсләр хас.

Мөҗәһит

18. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Скажите, пожалуйста, из какой страны вы приехали?
2) Расскажите, пожалуйста, о вашей стране.
3) Ты любишь слушать татарские песни?
4) Я готовлю татарские блюда.
5) Приходите к нам в гости.
6) Вчера мы встречались с татарами из Турции.
7) Вы хотите поговорить с учителем татарского языка?
8) Повторите, пожалуйста, кого вы хотите увидеть?
9) Я познакомился с девушкой из Австралии.
10) Татары из Китая очень гостеприимны.

19. Кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставляя нужные слова.

1) Иртән мин Кытайдан ... белән очраштым.
2) Көндез без Литва татарлары ... тыңладык.
3) Миңа Америкадагы татар диаспорасы ... бирегез әле.
4) Дустым Башкортстанда яшәүче ... сөйләшеп утыра.
5) Шәһәребезгә ... килделәр.

20. Сүзләр белән җөмләләр төзеп языгыз. Составьте и запишите предложения со словами.

Чит илдә, диаспора, сәбәп, ел, очрашалар, сөйләшәләр, мәгълүмат.

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Мин Кытайдан килгән татарлар ... таныштым.
1) белән 2) турында 3) соң

Алар татар ... булдылар.
1) китабында 2) театрында 3) ашларында

Без кичен татар җырлары ... .
1) алабыз 2) укыйбыз 3) тыңлыйбыз

Миңа ... ашы ошый.
1) токмач 2) чәй 3) чәк-чәк

Әбисе сугыштан соң ... киткән.
1) Төркиядә 2) Төркиягә 3) Төркиянең

Бу әфәндегә Литва татарлары турында ... бирегезче.
1) ипи 2) китап 3) каләм

Бу кеше ... сорыймы?
1) сине 2) безгә 3) аның

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, используя нужные окончания.

Дустың нәрсә турында китап укырга ярат...? Иртән син бара-бара нәрсә сөйлә...? Кичә әниең кем турында әйт... ? Иртәгә без дусларыбыз белән кафега барып кайт... . Үткән атнада дусларың белән кайсы театрга барып кайт...? Миңа Башкортстандагы татарлар турында сөйләп бир... . Сездә Кытайдагы татарлар турында китап бар...?

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.
Чит илләрдә яшәүче татарлар турында сөйләгез.



СПОРТ БӘЙРӘМНӘРЕ. СПОРТИВНЫЕ ПРАЗДНИКИ

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Салих — яшь спортчы. Ул спорт мәктәбендә укый. Салих анда хоккей белән шөгыльләнә. Көн саен 5–6 сәгать тренировкалар була. Анда дөрес суларга, чыныгырга, дөрес итеп йөгерергә һәм башка спортчылар белән бер команда булып уйнарга өйрәтәләр.

Һәр спортчы сәламәт булырга һәм режимны сакларга тиеш. Шуңа күрә Салих бик тырыша. Аның Универсиада һәм Олимпия уеннарында катнашасы килә.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Диләрә, син җиңел атлетика белән шөгыльләнәсеңме?

— Әйе, Дилә, мин йөгерәм. Ә син спорт гимнастикасы белән шөгыльләнәсеңме?

— Әйе, кайдан белдең?

— Мин синең Универсиадада чыгышыңны күрдем. Син бик яхшы чыгыш ясадың бит.

— Рәхмәт, Диләрә.

3. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз. Прослушайте, повторите и запомните.

җиңел атлетика – легкая атлетика
чыгыш ясарга – выступать

төр – вид
физик күнегү – физическое упражнение

җиңәргә – побеждать
җиңелергә – проигрывать
беренчелек – первенство

җан атарга – болеть
җанатар – болельщик
көндәш – соперник

4. Үрнәк буенча диалог төзегез. Составьте диалог по образцу.

— Дамир, син спорт яңалыклары белән кызыксынасыңмы?
— Әлбәттә, Салават, мин спорт яңалыкларын һәрвакыт тыңларга тырышам.
— Син Олимпия уеннарын карап барасыңмы?
— Мөмкин булганда, карап барырга тырышам.
— Сиңа кайсы спорт төре күбрәк ошый?
— Йөзү һәм чаңгы эстафетасы күбрәк ошый.
— Үзең спорт белән шөгыльләнәсеңме соң?
— Әйе, йөзәм һәм кышын чаңгыда йөрим.

5. Үрнәк буенча үзегез турында әйтегез. Скажите о себе по образцу.

Мин сәламәт булырга телим. Шуңа күрә һәр көн физик күнегүләр ясыйм һәм спорт белән шөгыльләнәм. Мин көн саен иртән йөгерәм. Атнага ике тапкыр спорт секциясенә йөрим. Җәен — футбол, кышын хоккей уйныйм. Баскетбол, теннис, волейбол уйнарга яратам.

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? 2013 нче елда Казанда Универсиада үткәрелде.

...? 2014 елда Россиянең Сочи шәһәрендә Кышкы Олимпия уеннары узды.

...? Мин хоккей буенча Дөнья беренчелеге уеннарын яратып карыйм.

...? Дустым авыр атлетика белән шөгыльләнә.

...? Бүген Казанның «Рубин» командасы Төркиянең «Галатасарай» командасы белән уйный.

...? Гафу итегез, бу матчка билетлар юк.

...? Мин «УНИКС» баскетбол командасы өчен җан атам.

...? Мин бу ярышларда катнашмадым.

7. Текстны укыгыз һәм үрнәк буенча сөйләгез. Прочитайте текст и расскажите по образцу.

Безнең өйдән ерак түгел футбол кыры бар. Анда һәр көнне футболчылар ярышка әзерләнәләр. Алар анда футбол уйныйлар, физик күнегүләр ясыйлар. Без дә бу кырга еш барабыз һәм командаларның уеннарын карыйбыз. Яраткан командаларыбыз өчен җан атабыз.

Уеннар төрлечә тәмамлана. Кайбер көннәрдә командалар арасында исәп тигез була, ә кайбер көннәрдә бер команда икенчесен җиңә. Җиңүчеләр шатланалар, җиңелгән команда уенчылары моңсу булалбар. Ләкин алар көндәшләрен җиңү белән котлыйлар.

8. Сорауларга җавап бирегез. Ответьте на вопросы.

Малай кайсы спорт төре белән шөгыльләнә?

Кыз нишли?

Бу әфәнде кайсы команданың җанатары?

Истә калдырыгыз! Запомните!
Алгач — после того как взял; **җиңгәч** — после того как победил;
киткәч — после того как ушел; **кайткач** — после того как вернулся —
хәл фигыльләр (деепричастия)

9. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Универсиада уеннары башлангач, сез нинди ...? Ярышта җиңгәч, ул ...? Сезгә хәбәр иткәч, алар ... ? Син әйткәч, ул кайда ... ? Футбол уенын карарга баргач, ...? Иртән торгач, син кем белән ...? Тренировкалардан кайткач, ...? Син йөзү белән шөгыльләнгәч, ...? Ул «Ак барс» өчен җан аткач, ...?

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Олимпия уеннары тәмамлангач, ... Европа беренчелеге өчен ярышкач, ... Синең җиңүеңне белгәч, ... Командабыз яхшы булгач, ... Дустым авыр атлетика белән өч ел шөгыльләнгәч, ... Әнием әйткәч, ... Универсиада уеннарында катнашкач, ... Дустым ярышка киткәч, ... Абый алтын медаль алгач, ...

11. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Исәнме, Фәрит!

— Сәлам, Харис!



— Бүген Олимпия уеннарының ябылу тантанасы буламы? Мин шуны карарга килдем.

— Әйе, мин дә шуны карарга килдем. Кайсы ил командасының беренче буласын беләсем килә?

— Әйе, минем дә. Син Олимпия уеннарының барысын да карап бара алдыңмы?

— Юк, кызганычка каршы, барысын да түгел. Ә син?

— Мин дә чаңгы ярышларын һәм хоккей матчларын гына карый алдым.

— Ләкин бу ярышлар бик кызыклы булды. Мин Россия командалары өчен җан аттым.

— Мин дә. Бүген безнең ил командасы җиңүче була дип ышанам.

— Мин дә!

12. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— Сәлам!

— ...!

— Әйдә, фигуралы шуу буенча ярышлар карарга барабыз.

— ... . Алар кайда була?

— ... спорт комплексында. Ярым финал ярышлары сәгать ... башлана.

— Минемчә, безгә ... .

— Ярый, мин сине ... .

— Очрашканга кадәр!

13. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) ул, шуу, фигуралы, белән, өч, шөгыльләнә, ел.
2) әле, бармы, сездә, матчка, бүгенге, билетлар?
3) кирәк, һәр, иртән, көн, йөгерергә, бу, сәламәт, өчен.
4) ярата, барырга, кафесына, спорт, кичләрен, дустым.
5) бу, алтын, медаль, ярышларда, дустым, алды.

14. Яраткан командагызның спорт уены турында сөйләгез.
Расскажите об игре вашей любимой команды.



15. Сүзләрне яңа формада әйтегез һәм тәрҗемә итегез.
Образуйте новые формы слов и переведите их.

Шу — ..., җиң — ..., оттыр — ..., уйна — ..., кит — ..., ят ит — ..., сөйләш — ... .

-кач/-кәч, -гач/-гәч

Истә калдырыгыз! Запомните!

Алганчы — до того как взяли; **җиңгәнче** — до того как победили; **киткәнче** — до того как ушли; **кайтканчы** — до того как вернулись — **хәл фигыльләр** (деепричастия)

16. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген кыскача сөйләгез.
Прочитайте текст и перескажите его содержание.

Кышкы спорт төрләренә хоккей, чанада, чаңгыда һәм тимераякта шуу, фигуралы шуу керә. Әлбәттә, хәзер кышкы спорт төрләре белән җәен дә шөгыльләнергә мөмкин, чөнки спорт сарайларында ясалма боз бар. Кыш җиткәнче һәм көннәр суынганчы, анда рәхәтләнеп шөгыльләнергә була.

Кышын чаңгыда йөрү бик файдалы. Шуңа күрә кешеләр тауларга баралар һәм туйганчы чаңгы шуалар. Мин үзем чана шуарга яратам. Кыш беткәнче, без дусларым белән тауга барабыз һәм анда чана шуабыз. Бу тауда балалар гына түгел, зурлар да бик күп була.

Яз җиткәнче, без кышкы спорт төрләре белән шөгыльләнергә тырышабыз һәм вакытыбызны күңелле үткәрәбез.

17. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Прочитайте выразительно стихотворение.

Мин — спортчы

Мин иренмим беркайчан
Таңнан ук торып басам.
Кояш нурларын каршылап,
Тәрәзәләрне ачам.

Иртәнге салкын һаваны
Сулыйм да иркен итеп:
— Әйдә, — дим, — физзарядкага!
— Кулны канаттай җилпеп.
Курыкмыйм мин салкын суда
Йөзәргә дә уйнарга.
Чыныгырга яратам мин,
Авырмыйм мин шуңарга.

Резеда Вәлиева

18. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Скажите, пожалуйста, у вас есть билеты на сегодняшний матч?
2) Дайте, пожалуйста, два билета на фигурное катание.
3) Ты любишь смотреть соревнования по легкой атлетике?
4) Я каждый день по два часа занимаюсь спортом.
5) Я завтра буду участвовать в соревнованиях по теннису.
6) Вчера мы победили наших соперников.
7) Вы проиграли.
8) Я каждый день смотрел Олимпийские игры.
9) Он участвовал в универсиаде в Казани.
10) Мы вышли в полуфинал.

19. Кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, вставляя нужные слова.

1) Иртән мин ... ясыйм, ...
2) Атнага ике тапкыр ... йөрим.
3) Миңа фигуралы шуу белән ... .
4) Дустым ... карарга ярата.
5) Шәһәребездә ... кафелары күп.

20. Сүзләр белән җөмләләр төзеп языгыз. Составьте и запишите предложения со словами.

Җанатар, җан атарга, җиңәргә, җиңелергә, катнашырга.

☑ ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ! ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Мин ... белән шөгыльләнәм.
1) чана 2) тимераяк 3) теннис

Алар ярышларда беренче ... алдылар.
1) урын 2) җанатар 3) көрәш

Без кичен спорт кафесында ... .
1) пешерәбез 2) шуабыз 3) җыелабыз

Миңа ... шуу ошый.
1) тимераякта 2) футболда 3) волейболда

Әбием Олимпия ... карарга ярата.
1) уеннарын 2) утын 3) киемен

Ярышта беренче килгәч, бу әфәндегә ... бирделәр.
1) медаль 2) алкышлар 3) штраф

Кышкы Олимпия уеннарында миңа фристайл ... ошый.
1) зур 2) аеруча 3) күп

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, используя нужные окончания.

Дустым чаңгы ярышыннан кайт..., без аны котладык. Иртән син шалтырат..., мин бик сөендем. Кичә әни чакыр..., без тауга киткән идек. Иртәгә укуга бар..., без дусларыбыз белән спорт залга барырга тиеш. Үткән атнада дусларың белән чаңгы шу..., кайсы кафега киттегез? Миңа кышкы спорт төрләре... хоккей аеруча ошый. Бу спорт сарае... җиңел атлетика буенча ярышлар үткәрелә.

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.
Яраткан спорт уеннарыгыз турында сөйләгез.



КАЗАН БУЙЛАП СӘЯХӘТ. ПУТЕШЕСТВИЕ ПО КАЗАНИ

1. **Тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте и прочитайте.

Казан — зур һәм борынгы шәһәр.

Татарстанның башкаласы — тарихи шәһәр.

Казанга рәхим итегез!

2. **Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз.** Прослушайте диалог и прочитайте.

— Синең Казанда булганың бармы?

— Бар. Ә синең?

— Әйе. Казан миңа бик ошый. Ул тарихи истәлекләргә бай шәһәр.

— Син хаклы.



3. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз. Прослушайте, повторите и запомните.

корылма – сооружение
манара – башня
китапханә – библиотека

милли – национальный
мәшһүр – знаменитый

чиркәү – церковь
мәчет – мечеть
базар – рынок

сәүдә-күңел ачу үзәге – торгово-развлекательный центр

4. Үрнәк буенча диалог төзегез. Составьте диалог по образцу.

— Исәнмесез!
— Хәерле көн!
— Гафу итегез, сез Казаннанмы?
— Әйе.
— Ә мин Төркиядән килдем. Истанбулдан.
— Сез Казанда беренче тапкырмы?
— Юк, икенче тапкыр. Миңа университетка барырга кирәк.
— Кайсы университетка?
— Казан федераль университетына. Ярдәм итегезче, нинди транспорт яхшырак?
— Хәзер мин сезгә троллейбус тукталышын күрсәтәм. Анда 7 нче троллейбус бара.
— Рәхмәт сезгә.
— Сау булыгыз! Хәерле юл!

5. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Казан — ... шәһәр. Ул Иделнең сул ярында ... . Казанда ... урыннар күп. Казанның үзәгендә ... балкып тора. Бирედә Сөембикә ..., Кол Шәриф ..., Благовещение ... урнашкан. Шәһәребезгә ... күп килә. Алар ... булырга яраталар. Татарстанның ... рәхим итегез!

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Казан шәһәре истәлекле урыннарга бай.
...? Кунаклар Казанның тарихы белән кызыксындылар.
...? Казанда бер миллионнан артык кеше яши.
...? Ел саен Казан шәһәренә төрле илләрдән туристлар килә.
...? Казан шәһәрендә танылган театрлар, музейлар эшли.
...? Казанда ял итү һәм күңел ачу урыннары, спорт корылмалары күп.
...? Без Казан университетының төп бинасында очраштык.
...? Алар «Тандем» сәүдә-күңел ачу үзәгендә булганнар.

7. Текстны укыгыз һәм эчтәлеге буенча диалог төзегез.
Прочитайте текст и составьте по его содержанию диалог.

Казандагы иң матур биналарның берсендә Татарстанның Милли китапханәсе урнашкан. Аның каршында — мәшһүр Казан университеты. Ул 1804 нче елда ачылган. Анда атаклы галимнәр эшләгән, бөек ачышлар ясалган. Татарстанның башкаласында берсеннән-берсе матур биналар, истәлекле урыннар шактый күп. Алар арасында Милли музей, Сынлы сәнгать музее, Муса Җәлил исемендәге татар дәүләр опера һәм балет театры, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры һәм башкалар. Биредә ел саен Рудольф Нуриев исемендәге халыкара классик балет фестивале, Фёдор Шаляпин исемендәге халыкара опера фестивале, мөселман фильмнары фестивале үткәрелә.

8. Сорауларга җавап бирегез. Ответьте на вопросы.

Казанның истәлекле урыннары турында нәрсәләр беләсез?
Казанда иң танылган югары уку йортлары ниндиләр?
Казанда нинди фестивальләр үткәрелә?
Казанда нинди театлар, музейлар эшли?
Казанда туристларга нәрсәләр ошый?

Истә калдырыгыз! Запомните!

Урын-вакыт килешендәге исемнәр + *-гы/-ге, -гы/-ге* кушымчалары

(слова в местно-временном падеже + аффиксы *-гы/-ге, -гы/-ге*)

Казандагы — находящийся в Казани

шәһәрдәге — находящийся в городе

университеттагы — находящийся в университете

дәрестәге — находящийся на уроке

9. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Кунаклар Салих Сәйдәшев ... Зур концерт залында булганнар. Чит илләрдәге ... диаспоралары вәкилләре Казанда очрашты. Биш елга бер тапкыр Татарстанның ... Бөтендөнья Татар корылтае үткәрелә. ... дәресләрендә алар Казан Кремле турында сөйләштеләр. Кремль алдындагы мәйданда герой-шагыйрь ... һәйкәл куелган. Бүгенге Казан зур ул, матур ул, ... ул! Казан ... — Иделдәге иң эре портларның берсе. Казандагы зур рус драма театры ... исемен йөртә.

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Без Казан Кремле алдында ... . Шәһәр үзәгендәге тарихи биналар ... . Казансу елгасы буенда ... . Без елга портыннан ... . «Кольцо» сәүдә үзәгенә ... . Сөембикә манарасы — ... . Туристлар Татарстанның Милли музеенда ... . Казан университетында атаклы ... . Ирек мәйданында ... . Чит ил кунаклары Казанга ... .

11. Үрнәк буенча диалог төзегез. Составьте диалог по образцу.

— Исәнме, Алсу!

— Сәлам, Гөлинә!

— Алсу, синең Сынлы сәнгать музеенда булганың бармы?

— Юк әле, анда барырга вакытым булмады.

— Ә циркта?

— Циркта булдым. Миңа бик ошады.

— Мин дә күптән түгел анда яңа программа карадым.

12. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— Хәерле көн!

— ...! Кичә син ... бардың?

— Мин ... булдым.

— Ошадымы?

— Бик ... булды. Анда ... һәм ... бар.

— Ә ... күрдеңме?

— Әйе. Алар ... һәм ... .

13. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) театрлар, китапханәләр, бар, Казанда, танылган, музейлар.
2) экскурсовод, тарихи урыннары, таныштырды, туристларны, Казанның, белән.
3) үзәкләрендә, ошый, сәүдә-күңел ачу, йөрү, аеруча, миңа, Казанның.
4) балалар, зоопаркка, яраталар, аквапаркка, йөрергә, Курчак театрына.
5) яңа, бар, корылмалары, Казанда, нинди, спорт?

14. Кремль рәсеменә карагыз һәм аның турында сөйләгез.
Посмотрите на рисунок Кремля и расскажите о нём.



15. Яңа сүзләр төзеп әйтегез һәм тәрҗемә итегез. Образуйте новые слова и переведите их.

1) Горур — ..., тыныч — ..., биек — ..., гүзәл — ..., яшел — ..., патша — ..., чиста — ... .

2) Бүген — ..., хәзер — ..., кичә — ..., эч — ..., тыш — ..., ал — ..., арт — ... .

-лык/-лек
-гы/-ге, -кы/-ке

16. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген сөйләгез.
Прочитайте текст и перескажите его содержание.

Казан — тарихи шәһәр. Аның иң биек урынына Кремль диварлары урнашкан. Ә диварлар артында кызыл кирпечтән салынган Сөембикә манарасы һәм ап-ак Спас манарасы; Казаныбызга нур чәчеп торучы Кол Шәриф мәчете бар. Казан Кремле — Бөтендөнья тарихи мирас һәйкәле дип игълан ителде.

Казаныбызга мең яшь булуга карамастан, ул яшәрә генә бара, чөнки аны көннән-көн матурлыйлар. Башкалабызның иске урамнары, йортлары төзекләндерелә. Шулай ук яңа урамнар һәм микрорайоннар да калкып чыга. Казан һаман да иҗат дәрте белән рухланып яши, киләчәккә ачык йөз белән карый.

Казан — безнең республикабызның йөрәге ул, белем үзәге. Монда бик күп атаклы язучылар, галимнәр, рәссамнар, композиторлар яшәгән һәм иҗат иткән... Шәһәребездә бик күп танылган уку йортлары, музейлар, театрлар, китапханәләр бар. Казанда төрле халык вәкилләре үзара дус яшиләр һәм эшлиләр.

Казаным — ул дуслык шәһәре! Казаным — ул гел яңарып торучы, картаймый торган мәңге яшь шәһәр!

17. Шигырьдән өзекне сәнгатьле итеп укыгыз.
Прочитайте выразительно отрывок из стихотворения.

Пар ат

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап...
И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!..
Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.
Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан*, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

Габдулла Тукай

* **Гыйрфан** — культура.

18. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Вам приходилось бывать в Казанском Кремле?
2) Что находится на территории Казанского Кремля?
3) Какие исторические места Казани понравились вам больше всего и почему?
4) Какая площадь расположена в центре Казани?
5) Кто из знаменитых людей учился в Казанском университете?
6) Какие театры Казани вы посетили?
7) Чьё имя носит Татарский государственный академический театр?
8) Вы интересуетесь историей Казани?
9) Какие спортивные сооружения построили в Казани в 2013 году?
10) Какие торгово-развлекательные центры советуете нам посетить?

19. Кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, употребив нужные слова.

1) Казан — Россиянең иң матур ... берсе.
2) Казан — ... һәм ... шәһәр.
3) Унивеситетның борынгы ак таш бинасы ... урамында урнашкан.
4) Дустымның Сынлы сәнгать ... барасы килә.
5) Республикабызның Милли китапханәсе шәһәрнең иң матур ... санала.

20. Сүтезмәләр белән җөмләләр төзеп языгыз.
Составьте и запишите предложения со словосочетаниями.

Борынгы корылма, тарихи һәйкәл, мәһабәт мәйдан, Болгар мәчете, Пётр һәм Павел чиркәве, мәшһүр галимнәр, шәһәрнең горурлыгы.

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Казанның ... Кремль балкып тора.
1) борынгы 2) үзәгендә 3) алдында

Казан университетында бөек ... ясалган.
1) истәлекләр 2) галимнәр 3) ачышлар

Экскурсовод безгә Сөембикә ... тарихы турында сөйләде.
1) мәйданының 2) манарасының 3) мәчетенең

Иң матур биналарның берсендә Татарстанның ... китапханәсе урнашкан.
1) милли 2) мәдәни 3) фәнни

Казан — Татарстанның гына түгел, бөтен ... таралган татар халкының башкаласы.
1) авылга 2) шәһәргә 3) дөньяга

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, используя нужные окончания.

Көн саен Казан шәһәре... төрле илләрдән туристлар килә. Казан — тарихи һәйкәлләр... бай шәһәр. Башкала... үзәгендә, Казансу ярында Кремль урнашкан. Казан Кремле турында борынгы заманнар... ук тарихчылар сокланып язганнар. Элегрәк Кремль... төрле якларга чыгу өчен, унөч капка булган. Шуларның сигезе генә сакланган.

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.
Казанның истәлекле урыннары турында сөйләгез.



ТАТАРСТАН ШӘҺӘРЛӘРЕ. ГОРОДА ТАТАРСТАНА

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Татарстанда егерме шәһәр бар.

Иң зур шәһәрләр — Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән, Бөгелмә, Алабуга.

Алабуга — Татарстанның иң борынгы шәһәрләреннән берсе.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Сәлам!

— Сәлам! Әйдә, Татарстан шәһәрләрен һәм районнарын картадан табыйк әле.

— Яхшы. Менә кара, Арча, Әтнә, Балтач, Кукмара, Саба, Теләче, Мамадыш, Алабуга, Әгерже районнары республиканың төньягында урнашкан.

— Ә көньяктагы районнарны мин күрсәтәм. Кара. Менә Аксубай, Тәтеш, Спас, Норлат, Чирмешән районнары.

— Дөрес. Ә хәзер көнбатышта урнашкан районнарның исемнәрен әйт.

— Тыңла. Кайбыч, Апас, Чүпрәле, Буа районнары.

— Ә көнчыгышта?

— Актаныш, Минзәлә, Мөслим, Сарман, Азнакай, Бөгелмә һәм Баулы районнары.

— Хәзер кайсы районның кайда урнашканын яхшы беләбез.



3. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз. Прослушайте, повторите и запомните.

житештерергә – производить
исәпләнергә – насчитываться
икътисад – экономика

күп милләтле – многонациональный
халыкара – международный
мәгълүмат – информация

үсеш алырга – развиваться
чыгарылырга – вывозиться
кертелергә – ввозиться

мөнәсәбәт – отношение
өлкә – область
БДБ илләре – страны СНГ

4. Үрнәк буенча диалог төзегез. Составьте диалог по образцу.

— Алсу, син Татарстаннанмы?
— Әйе, мин Татарстаннан, Минзәләдән. Ә син, Дамир?
— Ә мин Арчадан.
— Татарстанның кайсы шәһәрләрендә булганың бар?
— Алабугада, Бөгелмәдә һәм Әлмәттә булганым бар һәм, әлбәттә, Казанда.

5. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Татарстанда шәһәрләр күп, ләкин мин ... . Һәр шәһәрдә ... . Казан шәһәрендә миңа ... . Минем Түбән Кама шәһәрендә ... . Күптән түгел алар Алабугага ... . Буа шәһәре ... . Татарстанның көньягында ... . Татарстанның зур шәһәрләре — ... . Түбән Кама — нефтехимиклар ... . Республикабыздан төрле илләргә йөк автомобильләре ... .

Истә калдырыгыз! Запомните!

-ыл/-ел/-л — фигыльнең төшем юнәлеше кушымчалары

(аффиксы страдательного залога глагола)

житештер — **житештерелә**	керт — **кертелә**
төзе — **төзелә**	чыгар — **чыгарыла**
яз — **языла**	эшлә — **эшләнә**
кабул ит — **кабул ителә**	башла — **башлана**
оныт — **онытыла**	ал — **алына**

яса — **ясала**

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Яр Чаллы шәһәрендә «КамАЗ» автомобильләре җитештерелә.

...? Алабуга шәһәрендә күп кенә күренекле кешеләр яшәгән.

...? Казан — күп милләтле шәһәр.

...? Минзәлә шәһәре Татарстанның көнчыгышында урнашкан.

...? Минем Чистай шәһәрендә булганым юк.

...? Яшел Үзән шәһәрендә «POZIS» суыткычлары эшләнә.

...? Татарстан чит илләр белән мөнәсәбәтләр урнаштыра.

...? Татарстанга башка илләрдән төрле товарлар кертелә.



7. Текстны укыгыз һәм эчтәлеге буенча диалог төзегез.
Прочитайте текст и составьте диалог по его содержанию.

Татарстан — икътисади үзәк. Татарстанда самолётлар, йөк автомобильләре, автомобиль шиннары, медицина җиһазлары, синтетик каучук, мех әйберләре җитештерелә. Татарстаннан төрле илләргә югары сыйфатлы товарлар чыгарыла. Республикага да күп кенә илләрдән төрле товарлар кертелә: авыл хуҗалыгы машиналары, төзелеш һәм юл техникасы, агач материаллары һәм башкалар. Татарстан Россия Федерациясенең өлкәләре һәм башка республикалары, шулай ук БДБ илләре белән мөнәсәбәтләр урнаштыра.

8. Сорауларга җавап бирегез. Ответьте на вопросы.

Татарстанда нәрсәләр җитештерелә?

Татарстаннан башка илләргә нәрсәләр чыгарыла?

Татарстанга нәрсәләр кертелә?

Татарстанның халыкара мөнәсәбәтләре турында нәрсәләр беләсез?

9. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Дәрестә без ... сөйләштек. Татарстанда югары сыйфатлы ... җитештерелә. ... районы Татарстанның төньягында урнашкан. Үткән атнада ... рәсми делегациясе Казанга килде.

Республикага башка илләрдән ... кертелә. Минем ... шәһәрендә буласым килә. Минемчә. Татарстанда ... шәһәр бар. Татарстанда иң борынгы шәһәрләрнең берсе — ... .

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Мин Татарстанның икътисады турында ... . Республика чит ил компанияләре белән ... . Татарстаннан төрле илләргә ... . Татарстан белән танышу өчен, ... Татарстанга килгәч, туристлар ... . Татарстанның төп сәүдә партнёрлары: ... . Түбән Кама шәһәрендә ... . Татарстанның Премьер-министры ... .

11. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Исәнме, Марат!

— Сәлам, Роберт!

— Марат, синең Яр Чаллыда булганың бармы?

— Кызганыч, юк әле.

— Ә Әлмәттә?

— Әлмәттә булдым. Миңа бик ошады. Бу — нефтьчеләр шәһәре.

12. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— Сәлам!

— ...! Син ... кайттыңмы?

— Әйе. Мин анда ...

— Ошадымы?

— Бик ... булды. Бу шәһәрнең тарихы ... .

— Кайларга ... ?

— ... булдым.

13. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) артык, район, вакытта, кырыктан, исәпләнә, хәзерге, Татарстанда.
2) Республикасы, Татарстан, буенда, Идел, урнашкан.
3) төньягында, Әгерҗе, республиканың, районнары, Балтач, урнашкан, һәм.
4) яшиләр, халыклар, дус-тату, барлык, Татарстанда.
5) укыдым, Татарстанның, китап, мин, турында, икътисады, кызыклы.

14. Татарстан картасына карагыз һәм районнарның кайда урнашуын әйтегез.
Посмотрите на карту Татарстана и назовите, где расположены эти районы.

Актаныш районы, Арча районы, Тәтеш районы, Кайбыч районы.

15. Яңа сүзләр төзеп әйтегез һәм тәрҗемә итегез. Образуйте новые слова и переведите их.

1) Нефть — ..., икътисад — ..., тарих — ..., комбайн — ..., юл — ..., таш — ... .

-чы/-че
-чан/-чән

2) Максат — ..., эш — ..., таләп — ..., кызыксыну — ..., кайгырту — ... .

16. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген сөйләгез.
Прочитайте текст и перескажите его содержание.

Татарстан Республикасының төп халкы — татарлар. Аларның саны 50 проценттан күбрәк. Республикада шулай ук руслар, чуваш, мордва, мари, удмурт, башкортлар һәм башка милләт халыклары яши.

Татарстанда БДБ илләреннән, башка өлкәләрдән һәм республикалардан килеп эшләүче һәм яшәүчеләр дә шактый күп. Алар арасында үзбәкләр, кыргызлар, азәрбайҗаннар, әрмәннәр, төрекләр һәм башка милләт вәкилләре бар. Республикабызда барлык милләтләр дус-тату яшиләр. Алар бер-берсенең гореф-гадәтләрен, милли бәйрәмнәрен беләләр, бергә бәйрәм итәләр.

17. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Прочитайте выразительно стихотворение.

Татарстан җирләре

Самолетта очып барам
Якынлашкандай Айга.
Тәрәзәдән җиргә карыйм:
Әй кызык икән анда!
Әнә Бөгелмәм, Казаным —
Күренә минем Ватаным!
Факеллар нурланып яна,
Күрәм нефть фонтанын.
Кама заводлары артта,
Идел дәрьясы унда.

Әнә Зәйдә су керәләр,
Мин һаман юлда, юлда.
Тагын нефть вышкалары
Әлмәттә, Азнакайда.
Кырларда иген өлгергән —
Шатлык кына һәркайда!

Әдхәт Синегулов

18. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Он — владелец торговой фирмы.
2) До приезда в Казань они жили в Елабуге.
3) Вы впервые в Казани?
4) На улицах Казани всегда много машин и людей.
5) Я горжусь достопримечательностями своего города.
6) В нашем городе строят новые спортивные сооружения.
7) Мы встретились на площади Свободы.
8) Молодежь республики активно участвует в общественной жизни.
9) Вот интересная статья про экономику страны, вы сможете использовать ее для вашего доклада.
10) Агрызский район находится на северо-востоке Республики Татарстан.

19. Кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, употребив нужные слова.

1) Татарстанда ... җитештерелә.
2) Монда төрле ... яши.
3) Татарстан Республикасының төп халкы — ... .
4) Республикабызда барлык ... дус-тату яшиләр.
5) Татарстан халыклары ... бәйрәмнәрне бергә билгеләп үтәләр.

20. Сүзтезмәләр белән җөмләләр төзеп языгыз.
Составьте и запишите предложения со словосочетаниями.

Күп милләтле республика, машиналар җитештерелә, Татарстанның төньягында, мөнәсәбәтләр урнаштыра, төрле өлкәләр, БДБ илләре.

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

1. Татарстанда ничә дәүләт теле бар?
   а) 3
   ә) 2
   б) 1
2. Кайсы шәһәр Татарстанның башкаласы?
   а) Яр Чаллы
   ә) Алабуга
   б) Казан
3. Татарстанда ничә район бар?
   а) 43
   ә) 49
   б) 37
4. Татарстанда ничә шәһәр?
   а) 15
   ә) 20
   б) 33

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, используя нужные окончания.

Туристлар Казан шәһәре... килергә яраталар. БДБ илләре ... Татарстанга төрле товарлар кертелә. Алабуга шәһәре... тарихы бик борынгы. Җәен без Бөгелмә шәһәре... кунакта булдык. Чистай... кайткач, мин дусларым белән очраштым. Хәзер алар Әлмәт шәһәре... яшиләр, элек Яр Чаллы... торганнар. Минем Әгерҗе районы... булганым юк.

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.
Интернеттан мәгълүмат табып, Татарстандагы бер шәһәр турында сөйләгез.

ТАТАРСТАННЫҢ ТАБИГАТЕ. ПРИРОДА ТАТАРСТАНА

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Татарстанның табигате бик матур.

Татарстанда зур елгалар да, матур күлләр дә күп.

Без Татарстанның табигатенә сокланабыз.

Табигатьне сакларга кирәк, чөнки ул — сәламәтлек нигезе.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Син урманда булырга яратасыңмы?

— Әлбәттә.

— Урманга еш барасыңмы?

— Җәен еш барабыз.

— Урманда нишлисез?

— Җәен җиләк, гөмбә җыябыз. Кышын урманда чаңгы шуабыз.

3. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз. Прослушайте, повторите и запомните.

урман – лес
җил – ветер
кояш – солнце

кар – снег
елга – река
яңгыр – дождь

болыт – облако
кыр – поле
тигезлек – равнина

дала – степь
салават күпере – радуга

4. Үрнәк буенча диалог төзегез. Составьте диалог по образцу.

— Син авылда ял итәргә яратасыңмы?

— Әлбәттә. Авылда һава саф һәм чиста.

— Авылда туганнарыгыз бармы?

— Әйе. Әбием авылда яши. Аңа 83 яшь. Без аңа кунакка кайтырга яратабыз. Җәйге ялны шунда үткәрәбез.

5. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Көн кояшлы булса, без ... . Көз җиткәч, кошлар ... . Кешеләргә, үләннәргә, хайваннарга ... . Елгалар һәм күлләр — ... . Шәһәрдә яшеллек күп булса, ... Татарстан кырларында ... . Һәр кеше туган якның табигатен ... .

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Татарстанда урманнар күп.

...? Татарстан елга-суларга бик бай.

...? Татарстан аша Идел, Кама, Нократ, Агыйдел елгалары ага.

...? Урманнарда аю, бүре, төлке, куян һәм башка хайваннар яши.

...? Яңгырдан соң салават күпере чыга.

...? Көзен көннәр җилле һәм яңгырлы була.

...? Бүген көн аяз.

...? Җәен мин авылда ял итәргә яратам.

7. Текстны укыгыз һәм эчтәлеге буенча диалог төзегез.

Прочитайте текст и составьте диалог по его содержанию.

Татарстанның табигате матур, бай һәм төрле. Калын урманнар да, тигез далалар да бар анда. Урманнарда төрле агачлар үсә. Агачлар арасында төрле хайваннар яши: аюлар, бүреләр, төлкеләр, куяннар.

Татарстан аша дүрт елга ага: Идел, Кама, Нократ, Агыйдел. Кечкенә елгалар һәм күлләр дә күп. Алар — безнең зур байлыгыбыз. Кешеләр елга, күл буйларында ял итәргә яраталар.

Татарстанның климаты уртача. Кышын Татарстанда артык салкын түгел. Ә җәен артык эссе булмый.

8. Сорауларга җавап бирегез. Ответьте на вопросы.

Татарстанның табигате нинди?

Татарстан аша нинди елгалар ага?

Татарстанда нинди күлләр бар?

Татарстан урманнарында нәрсәләр үсә?

Татарстанның климаты нинди?

Сиңа Татарстанның табигате ошыймы?

Истә калдырыгыз! Запомните!

Кемдер, нәрсәдер, кайдадыр, кайчандыр, ниндидер, ничектер;
әллә кем, әллә нәрсә, әллә кайда, әллә нинди, әллә ничек;
кем дә булса, нәрсә дә булса, кайчан да булса —
билгесезлек алмашлыклары (неопределённые местоимения)

9. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Миңа кемдер телефоннан ... . Авыл янында нәрсәдер ... . Дустым каядыр ... киткән, миңа хәбәр итмәде. Алар кайчандыр ... булганнар. Ул әллә нәрсә әйтте, мин ... . Җылы якка баргач, без әллә нинди ... күрдек. Кичә кем дә булса ... елга буена ...? Сез урманда нәрсә дә булса ...? Киләсе якшәмбедә кая да булса ...?

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Без ниндидер тапшыру карадык, анда ... . Әллә кайчан минем Мәскәү зоопаркында ... . Кем дә булса Татарстанның табигате турында ...? Синең кайчан да булса Байкал күлендә ...? Табигатьне саклау өчен, син нәрсә дә булса ...?

11. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Сәлам, Миләүшә!

— Сәлам, Камил!

— Миләүшә, син авылга кайтасыңмы?

— Әйе. Анда минем әбием яши.

— Авылда нишлисең?

— Дусларым белән күлдә су коенабыз, урманда җиләк җыябыз.

— Син авылны яратасыңмы?

— Бик яратам.

12. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— Син ... булырга яратасыңмы?

— Бик яратам.

— ... еш барасызмы?

— Артык еш түгел.

— ... нишлисез?

— ... җыябыз.

13. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) чиста, саф, авылда, һава, һәм.
2) урманнарга, елгаларга, тауларга, бай, Татарстан.
3) табигать, нигезе, сәламәтлек, чиста.
4) нинди, күргәннәр, урманда, алар, җәнлекләрне, әллә.

14. Россия картасына карагыз һәм иң зур елгаларны һәм шәһәрләрне атагыз.
Посмотрите на карту России и назовите самые крупные реки и города.

15. Яңа сүзләр төзеп әйтегез һәм тәрҗемә итегез. Образуйте новые слова и переведите их.

1) Эш — ..., уй — ..., җыр — ..., ремонт — ..., тигез — ..., сый — ..., баш — ... .

2) Заман — ..., яшь — ..., сыйныф — ..., авыл — ..., юл — ... .

-ла/-лә
-даш/-дәш
-таш/-тәш

16. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген сөйләгез.
Прочитайте текст и перескажите его содержание.

Татарстанның табигате матур, бай һәм төрле. Калын урманнар да, тигез далалар да бар анда. Урманнарда төрле агачлар үсә. Агачлар арасында төрле хайваннар яши: аюлар, бүреләр, төлкеләр.

Татарстанның климаты уртача: кышлары артык салкын түгел, ә җәйләре артык эссе булмый. Шуңа күрә республиканың бай табигате игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнү өчен бик уңайлы.

Чиста табигать — сәламәтлек нигезе. Шуңа күрә аны сакларга кирәк.

17. Шигырьдән өзекне сәнгатьле итеп укыгыз.

Прочитайте выразительно отрывок из стихотворения.

Минем бакчам

Иркен һәм матур да
Безнең Туган илебез.
Урманга бай, суга бай
Гөлбакчалы җиребез.

Әминә Бикчәнтәева

18. Кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне языгыз.

Напишите предложения, употребив нужные слова.

1) Авылда һава ... һәм ... .
2) Табигатьне саклау — һәр кешенең ... .
3) Без урманда ... . җыябыз.
4) Кешеләр табигый байлыкларның кадерен белергә ... .
5) Без ... буенда ял итәргә яратабыз.

19. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Там вас ждет какой-то человек.
2) Кто-нибудь купил книгу этого автора?
3) Мне нужен какой-нибудь учебник.
4) Вам кто-то звонил из Москвы.
5) Когда-то я был в этом районе.
6) Он куда-то уехал.
7) Сегодня кто-нибудь придет к нам?
8) Мне кто-нибудь звонил?
9) Мы где-то забыли свой блокнот.
10) Когда-нибудь мы еще встретимся с вами.

20. Сүзтезмәләр белән җөмләләр төзеп языгыз.

Составьте и запишите предложения со словосочетаниями.

Кыргый хайваннар, урман кошлары, саф һава, табигатьне саклау, табигый байлыклар, тигез далалар, биек таулар, чиста күл.

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Татарстан аша ничә зур елга ага?

1) дүрт 2) алты 3) ике

Татарстанның климаты ... .

1) салкын 2) эссе 3) уртача

Татарстан урманнарында ... яши.

1) фил 2) песи 3) бүре

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, используя нужные окончания.

Табигать... саклау өчен, нәрсәләр эшләргә кирәк? Яшәү өчен, һәркем... нәрсә кирәк? Сез табигать... ял итәргә яратасызмы? Табигать без... нәрсәләр бирә? Республикабызның елгалары нәрсә... бай? Татарстан урманнары... нинди агачлар үсә? Сез... туган ягыгызның табигате ошыймы?

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.

Татарстанның табигате турында сөйләгез.



ҮСЕМЛЕКЛӘР ДӨНЬЯСЫ. МИР РАСТЕНИЙ

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Урманнарда төрле агачлар, чәчәкләр үсә.

Каен агачы — зифа буйлы. Ул бик күп төрле файда китерә. Язын яфраклары яшел. Көзен алтын шәл ябына.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Алсу, син нинди чәчәкләр яратасың?

— Мин ак чәчәк яратам.

— Ә миңа күкчәчәкләр күбрәк ошый.

3. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз. Прослушайте, повторите и запомните.

каен – береза
имән – дуб
чыршы – ёлка

нарат – сосна
кузгалак – щавель
гөлҗимеш – шиповник

үги ана яфрагы – мать-и-мачеха
энҗе чәчәк – ландыш

бака яфрагы – подорожник
күкчәчәк – василёк
чәчәк – цветок

агач – дерево
үлән – трава
тузганак – одуванчик
мәтрүшкә – душица

4. Үрнәк буенча диалог төзегез. Составьте диалог по образцу.

— Сәлам, Гүзәл!

— Сәлам, Лилия!

— Гүзәл, син нәрсә җыйдың?

— Мин үги ана яфрагы җыйдым.

— Ул нәрсәгә?

— Үги ана яфрагы бик файдалы. Ул төрле авырулардан саклый.

5. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Безнең урманнарда имән, каен, чыршы, нарат һәм башка ... үсә. Болыннарда үги ана яфрагы, мәтрүшкә һәм башка ... үсә. Дару үләннәре төрле авырулардан ... . Кычыткан — бик ... үлән. Әбием җәен ... җыя. Кышын без ... белән чәй эчәргә яратабыз.

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Гөлҗимештә витаминнар күп.

...? Урманнарыбызда имән, усак агачлары үсә.

...? Язын беренче булып умырзая чәчәк ата.

...? Кычыткан бакчаларда да үсә.

...? Җәен дару үләннәрен җыярга кирәк.

...? Яраткан чәчәгем — күкчәчәк.

7. Текстны укыгыз һәм эчтәлеге буенча диалог төзегез.
Прочитайте текст и составьте диалог по его содержанию.

Каен дөньяда ак кабыклы бердән-бер агач. Аның бу ак кабыгын туз диләр. Каенның суы дәва буларак та файдалы. Каен суында җимеш шикәре, алма кислотасы, аксымнар, С витамины, натрий, кальций, тимер була. Каенның яфраклары ревматизм, радикулит, буыннар авыртканда, бик нык ярдәм итә. Каен яфраклары төнәтмәсен йөткерү һәм шешенүдән дә файдаланалар. Аның кайнатмасы белән, чәч коелганда, баш юалар. Каен агачы үз энергиясе белән организмны терелтүгә сәләтле. Аның янына килеп баскач энергия агышын тоясың.

8. Сорауларга җавап бирегез. Ответьте на вопросы.

Каенның нинди файдалы сыйфатлары бар?

Каен кабыгы нинди төстә?

Сезнең каен суы эчкәнегез бармы?

Файдалы үләннәр турында нәрсәләр беләсез?

Яраткан чәчәкләрегез бармы?

9. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Бака яфрагы, кычыткан — бик файдалы ... . Без мәтрүшкә белән ... эчәргә яратабыз. Мәтрүшкәле чәй ... була. Гөлҗимештә С ... күп була. Мин үсемлекләр турында ... яратам. Яраткан чәчәгем — ... .

10. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Кычыткан латинчадан тәрҗемә иткәндә, ул «яндырам», «чагам» дигән мәгънәне ... . Татарча исеме дә чаккан урыны бик нык кычытканга күрә, «кычыткан» дип ... . Кычытканның 40–45 төре ... . Безнең якларда «икеөйле» дигән төре еш ... . Кычытканны язын җыярга һәм киптерергә ... . Әбием беренче кычытканнан аш пешерергә ... .

11. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Исәнме, Динә!

— Сәлам, Алинә!

— Динә, бу нәрсә?

— Бу — мәтрүшкә.

— Ә ул нәрсәгә?

— Мәтрүшкә — бик файдалы үсемлек. Әбием мәтрүшкәле чәй эчәргә ярата.

12. Диалогны тулыландырыгыз. Дополните диалог.

— Сәлам!

— ...!

— Кайдан кайтып киләсең?

— ... кайтып киләм.

— Анда нишләдең?

— ... җыйдым.

— Бик яхшы булган. ... файдалы бит.

— Әйе. Ул ... дәвалый.

13. Рәсемнәргә карагыз һәм дару үләннәрен атагыз.

Посмотрите на рисунки и назовите лекарственные травы.

14. Яңа сүзләр төзеп әйтегез һәм тәрҗемә итегез. Образуйте новые слова и переведите их.

Файда — ..., шифа — ..., мәтрүшкә — ..., чәчәк — ..., ылыс — ..., тәм — ... .

-лы/-ле

15. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген сөйләгез.

Прочитайте текст и перескажите его содержание.

Урман — табигый байлыкларының иң әһәмиятлесе. Урманнар Җир шарындагы кислородның өчтән бер өлешен бирә. Бу — кеше өчен яшәү, тормыш чыганагы. Урман — җирне эрозиядән саклый, дым белән туендыра. Урманнар булмаса, елга-күлләр кибәр иде. Шуңа күрә урманнарыбызны сакларга, аларны тагы да ишәйтергә кирәк. Эш менә нәрсәдә: урманнарда кар һәм яңгыр суы туфракка акрын сеңә һәм аннан үзенә юл табып, елгага агып төшә, аны «туендыра».

Кешеләргә урман үзенең матурлыгы белән чиксез зур шатлык китерә. Урманда ял итү кәефне күтәрә, кешенең сәламәтлеген ныгыта. Ә күпме гөмбә, җиләк, дару үләннәре бүләк итә ул безгә!

16. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Прочитайте выразительно стихотворение.

Гүзәл җирем

Гүзәл җирем,
Туган илем!
Нинди генә төс юк анда:
Аланында — алсу гөлләр,
Алтын кояш — кырларында.
Гүзәл җирем,
Туган илем!
Нинди генә моң юк анда:
Әрәмәдә — сандугачлар,
Кәккүк тавышы — урманында...

Резеда Вәлиева

17. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) В нашем саду много цветов.
2) Он сидел в саду, читая книгу.
3) Она любит полевые цветы.
4) Они любят работать в саду.
5) Наша страна богата лесами.
6) Если не будет дождя, мы завтра пойдем за грибами.
7) Береза, несомненно, одно из самых красивых деревьев.
8) Наступила осень, опали листья с деревьев.
9) Мы говорили о наших любимых цветах.
10) Эта книга содержит много полезных сведений.

18. Сүзтезмәләр белән җөмләләр төзеп языгыз.
Составьте и запишите предложения со словосочетаниями.

Каен урманы, киң болын, дару үләннәре, кыр чәчәкләре, яшел чыршы.

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Иң файдалы үләннәрнең берсе — ...

1) кычыткан 2) чүп үләне 3) кырык

Татарстан урманнарында ... үсә.

1) ишек 2) илле 3) имән

... чәй тәмле була.

1) Җилле 2) Мәтрүшкәле 3) Тозлы

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, используя нужные окончания.

Урманнар... «безнең планетаның үпкәсе» дип атыйлар. Урман үсемлекләр... кислород бүлеп чыгара. Урман һава... тузаннан да чистарта. Тузан агач яфраклары... утыра һәм яңгыр белән юыла.

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.

Урманның файдасы турында сөйләгез.



ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ. МИР ЖИВОТНЫХ

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Бүре соры төсле. Аның тешләре бик үткен. Ул урманда яши.

Бу — куян. Ул кышын ак, җәен соры төстә була.

Төлкенең койрыгы бик йомшак була.

Керпенең энәләре була.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Алсу, синең куян күргәнең бармы?

— Юк.

— Ә минем бар. Җәен без урманга җиләк җыярга бардык. Шунда куян күрдек.

3. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз. Прослушайте, повторите и запомните.

кыргый хайваннар – дикие животные
йорт хайваннары – домашние животные

сыер – корова
ат – лошадь
сарык – овца
кәҗә – коза

сыерчык – скворец
күгәрчен – голубь
чыпчык – воробей

кош – птица
әтәч – петух
тавык – курица

4. Үрнәк буенча диалог төзегез. Составьте диалог по образцу.

— Гафу ит, бу нинди кош?

— Бу — сыерчык. Ул — игенче ярдәмчесе.

— Ник алай дисең?

— Ул җәй буена уннарча мең корткычны юк итә.

— Сыерчыклар безнең якта яшиләрме?

— Сыерчыклар көзен көньякка китәләр.

5. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Чыпчыклар кешеләр янәшәсендә ... . Алар төрле шартларда ... . Оялары ... башында. Алар җәенә өч тапкыр ... чыгара. Чыпчыклар җиләк-җимеш агачларындагы бөҗәкләр белән ... .

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Тукранны «урман докторы» дип атыйлар.

...? Куян – иң куркак хайван.

...? Бүренең тешләре үткен.

...? Сыерчыклар көзен көньякка китәләр.

...? Кәҗә сөте бик файдалы.

...? Агач башында чыпчыклар чыркылдаша.

...? Әбием тавыкларны ашата.

...? Кышын кошларга ярдәм итәргә кирәк.

Истә калдырыгыз! Запомните!

Сыйфат фигыль (причастие)

Үткән заман сыйфат фигыль (причастие прошедшего времени):

алган; эшләгән, кайткан, киткән.

Хәзерге заман сыйфат фигыль (причастие настоящего времени):

1) ***ала торган, эшли торган, кайта торган; китә торган;***

2) ***алучы; эшләүче, кайтучы, китүче.***

Киләчәк заман сыйфат фигыль (причастие будущего времени):

1) ***алásы; бирәсе, сөйлисе; кабатлыйсы.***

2) ***алачак; эшләячәк, китәчәк; барачак.***

3) ***алыр; бар+ыр,эшлә+р; кил+ер; яз+ар.***

7. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Мин алган китапта ... турында бик күп мәгълүмат бирелгән. Университетта эшләүче галимнәр төрле ... алып баралар. Ул карый торган ... «Хайваннар дөньясында» дип атала. Син сөйлисе доклад нинди ... багышланган? Төркиядә яшәүче дустым ... булырга хыяллана. Сиңа әйтәсе сүзләрем ... . Япониядән килгән орнитолог белән ... булды. Экология — хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын өйрәнә торган ... .

8. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Ябалак урманда ... . Ул көндез курми, ә төнлә тычканнарны ... .

Тукран — урман ... . Ул агачларны ... . Песнәк — кечкенә ... . Ул кара, сары төсле ... . Песнәк безнең якта кышлый, көньякка ... .

9. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) агачлар, яши, төрле, хайваннар, арасында.
2) бөҗәкләр, кошлар, белән, туклана.
3) өйрәнә, тормышын, кошлар, орнитологлар.
4) булдык, утравында, экспедициядә, Сахалин, фәнни, без.

10. Рәсемнәргә карагыз, хайваннарны һәм кошларны атагыз.
Посмотрите на рисунки, назовите животных и птиц.



11. Текстны укыгыз һәм эчтәлеген сөйләгез.
Прочитайте текст и перескажите его содержание.

Безнең як урманнарында керпеләр, куяннар, төлкеләр, тиеннәр яши.

Керпе — бик чәнечкеле җәнлек. Аның бөтен тәне энәләрдән тора. Ул гөмбәләр, алмалар ярата. Аларны, кышка хәзерләп, җир астына күмеп куя. Керпе, ерткыч

җәнлекләрдән сакланыр өчен, түгәрәк шар формасын ала. Ул еланнардан да курыкмый. Еланнарның башларына ташлана. Керпе сукыр тычканнар белән дә туклана. Ул үзенең балаларын бик ярата.

Куяннар ике төрле була: йорт куяннары һәм кыр куяннары. Йорт куяннарын ит, тире һәм мамык өчен үстерәләр. Куян ите — бик файдалы диетик ризык, ә мамыгыннан шәлләр, бияләйләр бәйлиләр. Кыр куяннары кышын ак, ә җәен соры төскә керәләр. Бу аларга дошманнарыннан качарга ярдәм итә, чөнки куяннар бик куркаклар. Алар йоклаганда да, бер күзен ачып, берсен йомып йоклыйлар икән.

Хәйләкәр төлкене без әкиятләрдән, җырлардан, табышмаклардан ишетеп беләбез. Анда ул акыллы, хәйләкәр. Ул бик кызыксынучан. Төлке бик яхшы ишетә. Ул кырларда, урманнарда яши, кыр тычканнары белән туклана. Ул шулай кешеләргә файда да китерә, чөнки тычканнар кырдагы ашлыкны ашый. Төлке тагын бакаларны, вак кошларны ашый. Җәй көне үсемлекләр белән дә туклана. Урман-кырларда ризык җитмәсә, авылга килеп, тавык та алып китәргә мөмкин. Төлке — матур җанвар, купшы киенгән. Туны җылы, матур һәм калын.

Урман җәнлекләре елдан-ел азаеп бара. Аларны сакларга кирәк!

12. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Прочитайте выразительно стихотворение.

Бала һәм күбәләк

Бала:

Әйт әле, Күбәләк,
Сөйләшик бергәләп:
Бу кадәр куп очып
Армыйсың син ничек?
Ничек соң тормышың?
Ничек көн күрмешең?
Сөйләп бирче тезеп,
Табаламсың ризык?

Күбәләк:

Мин торам кырларда,
Болында, урманда;
Уйныймын, очамын
Якты көн булганда.

Иркәли һәм сөя
Кояшның яктысы;
Аш буладыр миңа
Чәчәкләр хуш исе.
Тик гомрем бик кыска:
Бары бер көн генә,—
Бул яхшы, рәнҗетмә
Һәм тимә син миңа!

Г.Тукай

13. Кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне языгыз.

Напишите предложения, употребив нужные слова.

Тиен кыш көне әзерләп куйган ... табып ашый. Ул — бик ... җәнлек. Үзенең оясын ... әзерләп куя. Дошманнарыннан тиз генә бер агачтан икенче ... сикереп кача.

14. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Поезд, который вы ждете, опаздывает на сорок минут.
2) Словарь, которым я пользуюсь, издан в Германии.
3) Возвращающимся из леса детям надо переходить дорогу.
4) Я забыл отправить письмо, написанное другу.
5) Друг, написавший мне письмо, сообщил о своей будущей работе.
6) Мне хочется общаться с людьми, говорящими по-татарски.
7) Знакомые, пришедшие к нам в гости вчера, рассказали об интересных растениях.
8) Ученики, правильно ответившие на все вопросы, получили пятёрки.
9) Я не нашел книгу, рекомендованную преподавателем.
10) Книга, которую вы ищете, сейчас на руках.

15. Сүтезмәләр белән җөмләләр төзеп языгыз.

Составьте и запишите предложения со словосочетаниями.

Хәйләкәр төлке, куркак куян, сыерчык оясы, сандугач сайравы, экологик куркыныч, сирәк очрый торган хайваннар.

☑ ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ! ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Аның туны кызыл.

1) бүре 2) куян 3) төлке

Татарстан урманнарында ... яши.

1) арыслан 2) керпе 3) фил

Орнитолог ... тормышын өйрәнә.

1) үсемлекләр 2) йорт хайваннары 3) кошлар

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, табышмакларны укыгыз һәм җавапларын әйтегез. Прочитайте загадки, используя нужные окончания, и отгадайте.

Җәен урман... патша,
Кышын кар... да аста.

Баш... тарак, койрыгы урак,
Кычкырып быргысын уята барын.

Сорыдыр төсе, үткендер теше,
Урман... йөри, бозаулар эзли.

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.

Интернеттан файдаланып, бер кыргый хайван турында сөйләгез.



СӘЯХӘТКӘ ЧЫГАБЫЗ. ОТПРАВЛЯЕМСЯ В ПУТЕШЕСТВИЕ

1. Тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте и прочитайте.

Кытайга сәяхәт бик кызыклы булды.

Сәяхәтчеләр юлга чыктылар.

Мин күренекле сәяхәтчеләр турында кызыклы тапшыру карадым.

Җәен без Кырым буйлап сәяхәт итәргә җыенабыз.

Кунакханәдә бер кешелек номерга бронь ясадым.

Иртәнге аш юллама бәясенә керә.

2. Диалогны тыңлагыз һәм укыгыз. Прослушайте диалог и прочитайте.

— Алсу, син былтыр кайда ял иттең?

— Чехиягә бардым.

— Кем белән?

— Дусларым белән.

— Кайсы шәһәрдә булдыгыз?

— Прагада.

— Ошадымы?

— Искиткеч шәһәр. Аннан китәсе килмәде.

— Шулаймы? Минем дә барасым һәм үз күзләрем белән күрәсем килә.

3. **Тыңлагыз, кабатлагыз һәм истә калдырыгыз.** Прослушайте, повторите и запомните.

сәфәр – путешествие
сәфәр кылырга – путешествовать
юллама – путёвка

туристлык агентлыгы – туристическое агентство
урынга бронь ясарга – забронировать место

Берләшкән Гарәп Әмирлекләре – Объединенные Арабские Эмираты

Америка Кушма Штатлары – Соединенные Штаты Америки

Согуд Гарәбстаны – Саудовская Аравия

канәгать калырга – остаться довольным
рәхмәт белдерергә – выразить благодарность

бер урынлык номер – одноместный номер
өч йолдызлы кунакханә – трёхзвёздочный отель

4. **Үрнәк буенча диалог төзегез.** Составьте диалог по образцу.

— Гафу итегез, сезнең кунакханәдә ике кешелек номерлар бармы?
— Бар. Ничә көнгә кирәк?
— Мин монда сигез көн булачакмын.
— Яхшы.
— Гафу итегез, иртәнге аш юллама бәясенә керәме?
— Әлбәттә.
— Мин номерымны карый аламмы?
— Әйдәгез, рәхим итегез.
— Бик әйбәт, бу номер миңа ошый.

5. **Җөмләләрне тулыландырыгыз.** Дополните предложения.

Дустым җәйге каникулда Америкага барырга ... . Аларның ... барасылар килә. Минемчә, сәяхәт күңелле итү өчен, ... Кунакханә безгә бик ..., без канәгать ... . Юллама алу өчен, без ... мөрәҗәгать иттек. Казанда туристлык агентлыклары ... . Университетны бетергәч, минем туристлык агентлыгында ... . Мин ... белән сәяхәт итәргә яратам.

Апам ... сәяхәт итәргә ярата. Безнең Скандинавия илләрендә ... . Без сезгә күңелле ... телибез.

6. Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Прочитайте предложения и задайте вопросы.

...? Минем Урта Азиядә булганым юк.

...? Дустым велосипедта сәяхәт итәргә ярата.

...? Алар Европа буйлап сәяхәткә чыгарга җыеналар.

...? Туристлар ике атна тауларда сәяхәт иткәннәр.

...? Җәйге ялым мартта була, һәм мин Таиландка барырга җыенам.

...? Әнием чит илләргә барырга яратмый, аңа авылда ял итү күбрәк ошый.

...? Аның Төркиядә булганы юк әле.

...? Кышкы ялда Япониягә сәфәр кыласыбыз килә.

Истә калдырыгыз! Запомните!

Ул нишли ала? Ул бара ала, килә ала, сөйли ала, тыңлый ала;

Ул нишли белә? Ул яза белә, әйтә белә, сөйли белә, тыңлый белә;

барып була, килеп була, сөйләп була, тыңлап була —

мөмкинлекне белдерә торган аналитик фигыльләр

(аналитические глаголы, выражающие возможность).

Ул бара алмый; ул яза белми; барып булмый —

юклык формасы (отрицательная форма).

7. Җөмләләрне тулыландырыгыз. Дополните предложения.

Алло, бүген сездә ... сатып алып буламы? Әйтегез әле, Казаннан Мәскәүгә ... белән барып буламы? Гафу итегез, сез ... турындагы сорауга җавап бирә алмыйсызмы? Әйтегез әле, бүген ... очып булырмы? Сез ... сәгать биштә каршылый алырсызмы? Дустың кунакханәдә беркешелек номерга ... аламы? Син велосипедта ... беләсеңме? Шәһәр картасын каян ... була? Быел җәен сез диңгезгә ... аласызмы?

8. Җөмләләрне дәвам итегез. Продолжите предложения.

Туристлар Прагадан Казанга ... . Сәяхәткә чыкканчы, кунакханәгә ... . Казаннан Кытайга ...? Җәен сез ничә көн ...? Ул иртәгә командировкага ...? Алар автобуста ...? Парижда нинди истәлекле урыннар белән ...? Буш вакытны файдалы үткәрү өчен, ...

9. Сүзләрдән җөмләләр төзегез. Составьте предложения из слов.

1) телим, сәяхәт, сезгә, мин, күңелле.
2) яраталар, машинада, алар, сәяхәт итәргә.
3) дәвам итте, атна, ялыбыз, ике, җәйге.
4) бардык, диңгезгә, былтыр, белән, гаилә, без.

10. Рәсемнәргә карагыз, истәлекле урыннарның исемнәрен әйтегез.

Посмотрите на рисунки, назовите достопримечательности.

11. Кирәкле сүзләрне куеп, җөмләләрне языгыз.

Напишите предложения, употребив нужные слова.

Иртәгә синең ... барасың бармы? Дәресләр беткәч, безнең туристлык агентлыгына ... . Кич белән аның дуслары белән ... . Өйгә кайткач, сезнең кемгә ...? Якшәмбе көнне минем ... сатып аласым бар.

Истә калдырыгыз! Запомните!

Кирәклекне белдерә торган аналитик фигыльләрнең зат-сан белән төрләнүе.

Спряжение аналитических глаголов, выражающих необходимость

Минем барасым бар (юк)	эшлисем бар (юк)
Синең барасың бар (юк)	эшлисең бар (юк)
Аның барасы бар (юк)	эшлисе бар (юк)
Безнең барасыбыз бар (юк)	эшлисебез бар (юк)
Сезнең барасыгыз бар (юк)	эшлисегез бар (юк)
Аларның барасылары бар (юк)	эшлиселәре бар (юк)

12. Сөйләм гыйбарәләрен тыңлагыз, укыгыз һәм истә калдырыгыз.

Прослушайте устойчивые выражения, прочитайте их и запомните.

— Ашыгыз тәмле булсын!

— Бергә булсын!

***

— Табыныгыз мул булсын!

— Рәхмәт, шулай булсын!

***

— Өстәлегез түгәрәк булсын!

— Рәхмәт, сезнеке дә шулай булсын!

***

— Чәйләрегез баллы булсын!

— Рәхмәт!

***

— Рәхмәт, бик тәмле булган!

— Исән-сау булыгыз!

13. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз. Прочитайте выразительно стихотворение.

Каникул

Кайчан килгән икән ул?
Кайчан киткән икән ул?
Рәхәт тә бит каникул,
Бигрәк кыска икән шул!

Резеда Вәлиева

14. Тәрҗемә итеп языгыз. Переведите и напишите.

1) Извините, к кому можно обратиться?
2) Ты можешь кататься на горных лыжах?
3) Он может поговорить с родителями об отдыхе?
4) Объясните, пожалуйста, как можно доехать до железнодорожного вокзала.
5) Вы умеете плавать?
6) В прошлом году он ездил в Италию.
7) Мне нужно купить два билета до Москвы.
8) Ему нужно забронировать номер в гостинице.
9) Вам что нужно купить в киоске «Сувениры»?
10) Кому нужно доехать до Перми?

15. Сүзтезмәләр белән җөмләләр төзеп языгыз.
Составьте и запишите предложения со словосочетаниями.

Дөньякүләм танылган шәһәрләр, теплоходта сәяхәт итү, ун көнлек сәяхәт, җәен ял итә алу, диңгезгә барып булу, алдан билет алып кую, биш йолдызлы кунакханәдә яшәү.

☑ **ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ!** ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ!

1. Дөрес җавапны табыгыз. Найдите правильный ответ.

Эйфель манарасы ... урнашкан.

1) Германиядә 2) Франциядә 3) Испаниядә

Төркиянең башкаласы — ... .

1) Истанбул 2) Прага 3) Әнкара

Без ... кунакханәдә яшәдек.

1) өч баскычлы 2) биш йолдызлы 3) дүрт бүлмәле

2. Кирәкле кушымчаларны куеп, җөмләләрне языгыз.
Напишите предложения, используя нужные окончания.

Номер өчен бер тәүлек... күпме түләргә кирәк? Иртәнге аш юллама бәясе... керәме? Мин машинам... кая куя алам? Багажым... номерга кертеп куегызчы. Иртәнге аш сәгать ничә...? Икенче килгәндә дә, мин сезнең кунакханә... тукталырмын. Без уналтынчы августта сәяхәт... кайтабыз. Быел аларның таулар... ял итәселәре килә. Сезнең Канада.. булганыгыз бармы? Мин поезд... сәяхәт итәргә яратам.

3. Коммуникатив бирем. Коммуникативное задание.
Иң күңелле сәяхәтегез турында сөйләгез.

ГОМУМИ ТЕСТ

I. ГРАММАТИКА

1. Җөмләләрне тулыландырыгыз.

1. Мин ... мәкалә бик кызыклы.
2. Бу кеше хикәя ... утыра.
3. Минем мәкалә ... бар.

(А) язып
(Б) яза торган
(В) язучы
(Г) язасым

4. Син әйтсәң, мин ...
5. Син әйтсәң дә, мин ...
6. Син әйттең, һәм минем ... килә.

(А) эшлисем
(Б) эшләрмен
(В) эшләмәдем
(Г) эшләячәк

7. Кибеткә кереп, ул ашамлыклар ...
8. Ашханәгә кергәч, ул бернәрсә дә ...
9. Сеңлем әйберләрне сорап ...

(А) алып
(Б) алды
(В) алмады
(Г) алса

10. Көн җылы, ... кояш юк.

(А) һәм
(Б) ләкин
(В) чөнки

11. Ял көнне эссе булды, ... без су коендык.

(А) әгәр
(Б) ләкин
(В) һәм

12. Кичә мин дәрестә булмадым,... авырдым.

(А) ә
(Б) чөнки
(В) әгәр

13. Ул бик тырыша, ... татарча яхшы белә.
14. Бүген салкын, ... яңгыр ява.
15. Алсу — яхшы дус, ... аны яраталар.

(А) чөнки
(Б) шуңа күрә

16. Мин биремне эшләмәдем, ... вакытым булмады.

17. Әгәр дустым ..., без шахмат уйнарбыз.

(А) киләсе
(Б) килсә дә
(В) килсә

18. Дәресләр ..., без өйгә кайтабыз.

(А) бетеп
(Б) беткәч
(В) бетәргә

19. Туганнарым ... шатландылар.

(А) кайтуым
(Б) кайтуыма

II. УКУ

Текстны укыгыз һәм биремнәрне үтәгез.

Салих Сәйдәшев

Салих Сәйдәшев — профессиональ татар милли музыкасына нигез салучы.

Дирижер, пианист, педагог, җәмәгать эшлеклесе, талантлы композитор С.Сәйдәшев 1900 нче елның 3 декабрендә Казанда туа. Салих 11 яшендә ятим кала һәм җизнәсе Шиһап Әхмәров гаиләсендә тәрбияләнә. Бала вакытыннан ук музыка белән кызыксына башлый. Ш.Әхмәров малайны үзе белән татар спектакльләренә, әдәби-музыкаль кичәләргә алып бара, рояль бүләк итә.

Салихның беренче укытучысы талантлы музыкант, «Тукай маршы»ның авторы композитор Заһидулла Яруллин була. Салихның сәләтен күреп, З.Яруллин аны музыка коралларында уйнарга, иҗат итәргә, көйләр язарга өйрәтә.

С.Сәйдәшев музыкаль белемне Казан музыка училищесында ала. 1918 нче елда үз теләге белән армиягә китә. Хезмәтне тәмамлап, 1920 нче елда Оренбургка кайта. Анда музыка мәктәбендә эшли башлый. Бу мәктәп Оренбургның музыка сөюче татар яшьләрен, балаларны туплый. С.Сәйдәшев монда композитор буларак беренче адымнарын ясый.

1922 нче елда Казанга кайтып, С.Сәйдәшев Татар дәүләт драма театрында музыка бүлеге мөдире булып эшли башлый, дирижерлык итә. Композитор иҗатында театр өчен язылган музыка төп урынны алып тора. Ул төрле елларда бик күп драма-пьесага музыка яза.

Казанда С.Сәйдәшев исемендәге урам бар. М.Горький урамында композиторның музее эшли, башкаланың Зур концерт залы С.Сәйдәшев исемен йөртә...

Ярты гасыр вакыт узгач, С.Сәйдәшев яңадан калабызга кайтты, бу юлы мәгърур һәйкәл булып. 2005 нче елның 12 нче августында Казанның Татарстан һәм Сул Болак урамнары кисешкән урында, Тукай һәйкәленнән ерак түгел генә яраткан композиторыбыз С.Сәйдәшевкә һәйкәл ачылды. Дүрт метрлы бронза һәйкәл. Сәйдәш концерт костюмыннан, кулында дирижер таягы, уйчан карашы еракка төбәлгән... Бу көнне татарның ике бөек улы — Тукай белән Сәйдәш — икесе ике һәйкәл булып, бер-берсе белән яңадан күреште. Һәйкәл авторы — сынчы Мәхмүт Гасыймов. Ул — Россиядә дә, чит илләрдә дә билгеле шәхес.

Текстның эчтәлеген тулы һәм төгәл чагылдырган вариантны сайлагыз.

1. Салих унбер яшендә ятим кала һәм ... гаиләсендә тәрбияләнә.	А. әбисе Б. җизнәсе В. абыйсы
2. Салихның беренче укытучысы талантлы музыкант, «Тукай маршы»ның авторы ... була.	А. Заһидулла Яруллин Б. Солтан Габәши В. Нәҗип Җиһанов
3. С.Сәйдәшев музыкаль белемне ... ала.	А. Мәскәү сәнгать училищесында Б. Казан музыка училищесында В. Берлин консерваториясендә
4. 1922 елда Казанга кайтып, С.Сәйдәшев ... музыка бүлеге мөдире булып эшли башлый, дирижерлык итә.	А. Татар дәүләт драма театрында Б. Татар дәүләт опера театрында В. Курчак театрында
5. Казанның Татарстан һәм Сул Болак урамнары кисешкән ..., Тукай һәйкәленнән ерак түгел генә сөекле композиторыбыз С.Сәйдәшевкә һәйкәл ачылды.	А. мәйданда Б. урында В. шәһәрдә

III. ЯЗУ

Табигать һәм кеше арасындагы бәйләнешләр турындагы текстны укыгыз. Автор әйтергә теләгән фикерне белдереп, сорауларга җаваплар языгыз.

1. Табигать кешеләргә ничек ярдәм итә?
2. Татар халкы нинди табигать шартларында яши?

3. Татарстан Республикасын ни өчен «дүрт елга иле» дип атыйлар?
4. Татарстанның климаты нинди?
5. Табигатьне кем сакларга тиеш?

ЧИСТА ТАБИГАТЬ — СӘЛАМӘТЛЕК НИГЕЗЕ

Һәр кешенең чиста, матур урында яшисе һәм сәламәт буласы килә. Шуңа күрә кешеләр һәрвакыт табигать кочагына омтыла: ял вакытларында җиләк, гөмбә, чикләвек җыярга урманга ашыгалар, күл яки елга буена су коенырга китәләр, саф һавада, урамда йөрергә телиләр. Алар табигатьтән яңа эшләр өчен энергия алалар, борчулы вакыйгаларын онытып, җаннарына тынычлык табалар.

Һәр халыкка үзенең туган җире якын, кадерле. Галимнәр фикеренчә, кешенең нинди табигать чолганышында яшәвенә карап, аның характерын да билгеләп була, чөнки кеше — табигатьнең бер кисәге.

Татар халкы яши торган урынның табигате дә бик матур, бай, серле һәм төрле. Калын зур урманнар да, тигез далалар да бар анда. Урманнарда төрле агачлар үсә, шуңа күрә катнаш урманнар да, ылыслы урманнар да шактый. Куе агачлар арасында, куаклыкларда пошилар, аюлар, бурсыклар, бүреләрне очратасың. Төлкеләр, куркак куяннар да еш очрый.

Татарстан Республикасын «дүрт елга иле» дип йөрткәннәр. Аның аша Идел, Чулман (Кама), Агыйдел, Нократ (Вятка) елгалары ага. Кечкенә елгалар, күлләр дә күп анда. Алар зурлар өчен дә, балалар өчен дә бик уңайлы ял итү урыннары булып тора.

Татарстанның климаты уртача: кышлары артык салкын түгел, ә җәен бик эссе булмый. Шуңа күрә республиканың бай табигате, йомшак, саф һавасы иген үстерергә, терлек үрчетергә уңайлы. Киң болын-кырларда аллы-гөлле чәчәкләр, шифалы үләннәр бик күп. Татарстан кырларында бодай, арыш, кукуруз, карабодай, борчак, чөгендер, көнбагыш үстерәләр. Терлекчеләр мөгезле эре терлек үрчәтәләр, дуңгызчылык һәм кошчылык белән шөгыльләнәләр. Чиста табигать — сәламәтлек нигезе. Шуңа күрә һәр кеше аны карап, чистартып торырга тиеш. Кеше кайда гына булмасын: үз илендәме яки сәяхәттәме, чит җирдәме, табигатьне саклау — аның бурычы. Җир — безнең уртак йортыбыз!

IV. СӨЙЛӘҮ

1. Сөйләшүдә катнашыгыз. Әңгәмәдәшегезнең сорауларына җавап бирегез.

1. — Хәерле көн, Алмаз. Кәефегез юк, ахры. Нәрсә булды?
   — … .
2. — Сез татарча яхшы сөйләшәсез. Сез кайда өйрәндегез?
   — … .
3. — «Татарстан» кунакханәсенә ничек барырга?
   — … .
4. — Гафу итегез, бу «Мәскәү — Берлин» поездымы? Ул сәгать ничәдә китә?
   — … .
5. — Сез беләсезме, татар ашлары турында китапны кайдан алып була?
   — … .

2. Ситуациянең тасвирламасы белән танышыгыз. Сөйләшүне башлагыз.

1. Дустыгыздан иң якын милли ашлар кафесының кайда икәнлеген сорашыгыз һәм сезгә ни өчен кирәк булуын аңлатыгыз.

2. Сез спорт бәйрәмендә булдыгыз, ди. Күргәннәрегезне сөйләгез һәм мөнәсәбәтегезне белдерегез.

3. Сез чит шәһәргә килдегез, ди. Кунакханәдә урын алырга телисез. Кунакханә администраторы белән сөйләшегез.

4. Кичә сез «Татарлар» тапшыруын карадыгыз. Дустыгызга бу тапшыруны карарга тәкъдим итегез һәм ни өчен икәнен аңлатыгыз.

5. Сезнең Алабуга шәһәренә барасыгыз килә. Автовокзал кассасына шалтыратып, билетлар турында белешегез.